# БЕР ТОТКАРНЫҢ САТАШУЫ

Шәфика минем озын бүлмәмнең кәнәфиенә утырган да, минем соңгы әсәремнең төп нөсхәсене актара. Һәр битендә кеби туктый. Әллә нәрсә укымакчы була. Укый. Бит араларында зур күзен ачып миңа карый да:

— Ничек бу язуны типографиядә таныйлар?

— Аптырыйлар, йөдиләр дә, таныйлар, — дип башымдагы уйны бозмый гына җавап бирәм.

Шәфиканың баш өстендәге рәсемле ике ачык хатлар, куе кара сачының астында хәзер нинди уйлар йөргәнене белергә теләгән кеби, туп-туры аңар карап торалар. Анлар, бер-берсенең арасында дошманлыкмы, көнләүме сизенгән кеби, берсе-берсенә кыек күз белән генә күз төшерәләр. Берсене ерактагы бер татар кызы җибәрде дә, мин, матурсынып, баш очына кадап куйдым. Икенчесе — шуны күреп киткәннең соңында Шәфиканың җибәргән хаты! Икесе дә мәгънәле, икесе дә матур, икесе дә ике кызның да миңа аерым күз белән караганын күрсәтеп тора.

Шәфика акрын гына күзен күтәреп карый да, сәгатен ачып: «Күптән сәгать җиде!» — ди. Мин аның сүзене тәмамлаган кеби: «Күптән юлга чыгарга вакыт»,—дим дә, аның алдында басып торам. Ул: «Нишләрмез соң?» — дигән кеби карап тора.

Без икемез дә бер кызны, тагы бер татар кызыны, бер татар курсисткасыны көтәмез. Шәфиканы чакырган кеби, үземнең соңгы әсәремне уку мәҗлесенә, хат язып мин аны да чакырдым. Минем дустым-ишем бик күп: бик күп кешенең соңгы әсәремне тыңлыйсы килә, бик күп студентның, бик күп курсистканың шул мәҗлестән каласы килми.

Бөтен кешене җыярга урын да юк, мөмкин дә түгелгә, мин ике [тапкыр] укырга булам. Беренчесенә, дустлар арасыннан сайлап, бик озак уйлап, шул ике кызны чакыра алам. Өченчесе, дүртенчесе алдында үземне гаепле кеби күргәнгә, шунлардан кызарып, бүлмә буенда озын-озын атлап йөрим.

Зәйнәп килми дә килми. Мин, аның бүген зачеты бардыр, димен, чын да аның зачеты бардыр.

Ул бөтенләй Шәфикага башка. Ул да татар кызы, ул да Шәфика кеби, яше унсигез-унтугызга җиткәч, русча укый башлап, татар тормышының пәрдәсене, чаршавыны, чапаныны ертып чыккан, ул да көнене-төнене белмичә, өч елда имтихан тотып курска кергән. Икесе дә курсистка, икесе дә тырмашып-тырмашып, иске тормышның ярыкларына ябышып, шул тормышның өстенә чыккан татар кызлары.

Шәфика студентлар, курсисткалар арасыннан һич калмый, һич бер мәҗлес ансыз булмый. Зәйнәп әллә нидә бер генә килеп чыга, анда да соң килә, тиз китә, янына килеп, кулыны кыскан иптәш студентлар, курсисткаларының: «Син кая югалдың, Зәйнәп?» — дигән сөаленә: «Зачет бирдем, зачет бирәсем бар иде, зачет бирдем», — дип җавап бирә. Дустына-ишенә аның тормышында зачетсыз көн юк кеби сизелә. Ләкин аның өчен Зәйнәпне бер кеше дә гаепләми, берсе дә аның хакында начар фикергә керми. Студенты, курсисткасы— шунлар берлән бергә буталып йөри торган һәммәсе Зәйнәпне якын күрә, Зәйнәпне сөя. Һәммәсе дә аның йөзгә бер генә зачетсыз калган көнене урларга тырыша.

Шәфика тагы сәгатене карый. Аның шул эшенә җавап кеби, мин: «Вакыт!» — дим. Без китәмез. Зәйнәпкә өстәл өстенә хат язып калдырамыз: фәлән урамга, фәлән йортка, фәлән өйгә. Ләкин йортының нумиры дөрестме? Мин, уйлап торам да: «Ул йортта булмаса, күршесеннән сора», — дип төзәтәм.

Шәфикага пальтосыны тотып кигезәм. Үземнең хәтеремә безнең татарлардагы ирләр белән хатыннар арасындагы мөнәсәбәт килеп төшә. Бездә ирләр чыга башласа, хатыннар аягүрә тора, туныны, катасыны таба, бүрегене, башлыгыны кидерә, төймәләрене каптырып, билбавын урый. Минем әби дә минем бабай алдында шулай иткәндер, минем әби дә кич берлән бабайның читегене тарткандыр, иртә берлән казакиены, камзулыны, җиләнене кидергәндер. Ә мин үземнән яшь, үземнән түбән кыз алдында пальтәсене күтәреп торам.

Без хәзер башка: анлар иске татарлар, без яшь татарлар. Анларның ирләре, кызлары «бармак санаш», «йөзек яшерү», «кем сукты» уйнар өчен генә

җыелганнар, без әсәр укырга, татар тормышыннан, шул бабай, шул әбиләрнең тормышыннан язылган китап укырга җыеламыз. Анларның уйлаганнары: ат сугару, сыер саву, бала йоклату, киндер хәзерләү, ботка пешерү, май язу булган. Безнең төшенгәнемез: бөтен төрек-татарның, Себер сахраларыннан алып Төркстаннын кырыена кадәр, Кавказ тауларының аръягына кадәр булган төрек-татарларның иске тормышларына бизәк бирү, аның черегән йирләрене алып ташлап, яңа кештәк-ямау, яңа итәк, яңа чабу ясау. Ана карыныны ерткannан да күп көч әрәм итеп, чапаныны, җиләнене ертып чыккан менә шул Шәфикалар, Зәйнәпләр, Мәрьямнәр, Әминәләр, Мәдинәләр, Әсмалар, әллә кемнәр, әллә кемнәр шуны теләгән кеби, сасы мәдрәсәнең майлы, күмерле ишекләрене җимереп, татар тормышының диварын, энә берлән кое казыган кеби, көннәр-төннәр тырышып, еглашып, талашып, борыннары берлән боз тишеп чыккан егетләр, иске бабаларыннан калган еллаган бал кеби, бер савыты аяктан егарга җитә торган, көчне саклый торган синнәр, миннәр, Әминнәр, Дәминнәр — барымыз да шуны телимез, барымыз да шуңар хәзерләнәмез! Биленә кайчысын бәйләп, кулына энәсене тотып, кисәргә дә тегәргә хәзерләнгән шул кызга, кулына марлясыны, мамыгыны тотып, күлмәк кискәндә тырналган тәненә чыккан каныны юарга хәзер торган шул абыстайга кайсыңыз буенсынмас идеңез, кайсыңыз киемене тотып тормас идеңез?..

Хезмәтче кызга өстәлдә хат барын әйтеп, ишектән чыгамыз. Әйләнмәле-әйләнмәле, эт, мәче исе килә торган баскычтан төшә башлыймыз, ашыга-ашыга күзе күрмәс булган Зәйнәпкә аз гына бәрелмимез. Ул гаепле-леген сизенгән кеби: «Мин ашыга-ашыга эштән чыктым, арба алып килдем, бүген минем зачет бар иде», — ди. Без икемез дә аннан көләмез, ул үзе дә көлә. Зур киң урам безне дә кочаклап ала. Эчләрендә әллә нинди уйлар саклый торган шул кызларны, дөньяның астын өсткә әйләндерергә уйлый торган шул мөхәррирне урам үзенең көче берлән кысып, керче хатын, дворник, приказчик берлән әрләштерә, берләндерә. Ашыга-ашыга китәмез. Юл буе Зәйнәп үзенең: «Калам, калам!» — дип курыкканымы сөйли. Бөгәрләп төрелгән төп нөсхәне

Шәфика, кулыннан төшермиче, Абелхәятне тапкан кеше кеби һаваланып, башын күтәреп алга таба бара.

Менә зур йорт. Менә зур көзгеле өй алды. Генералча киенгән ишекче. Менә моң гына выжлый-улый торган югары чыгарга машина. Ачык ишек безне каршы ала. Электрик лампалары, безнең эчемездәге фикерләрне белгән кеби, безнең шул уйларымызны тутырыр өчен, төнге-көнге яктылыкка мохтажлыгымызны сизенгән кеби, үзенең матур, моң яктысында коендыра. Бөтен җиһазы зәңгәрчә ясалган бүлмә электрик яктысында һәммәмезгә дә әллә нинди зәңгәр сыманрак төс бирә. Уйлар, фикерләр, идеяләр — һәммәсе дә зәңгәрчәрәк төскә керә.

Менә бер кыз, тагы бер татар кызы рояльдә уйнарга тотына, рояльнең нечкә, нәзек тавышлары тамырлар, сеңерләр буенча агып йөреп бөтен тәнгә зәңгәрчә рәхәт таралта, рәхмәт фәрештәсе кеби сөенеп, шатлык сибә.

Менә бар да хәзер, бар да килде. Әллә нинди бик зур парахут планын ясап, бүген-иртәгә шуның очына чыгып, инженер була торган егет тә бунда. Буыннар, тамырлар, сеңерләр, сөякләр, җилекләрне санап бетереп, анларның кыегаюыннан, кәкрәюеннәнниләр булганны бүген-иртәгә санап бетереп, шунларны төзәтергә китәргә хәзерләнә торган кыз да монда.

Йомшак кына музыка тавышы безне зур залга озата. Озын өстәл өстенә чәй хәзерләнгән. Самавыр моң гына иттереп көйләп, буын чыгарып ята. Чынаягы подносына охшаган, подносына, тәрилкәсенә пар килгән шикелле төзелгән өстәл безне көтеп тора. Барымыз да утыарамыз.

— Укыйкмы?

Хуҗа абыстай:

— Укыйк! — ди.

Мин акыртын гына кәгазьләрне тарата башлыйм. Тын. Кызлар, егетләрнең күзләре генә миңа таба текәлгән дә, беренче тавышны төшереп җибәрмәс өчен кеби, һәммәсе зур дикъкать берлән көтәләр. Электрик лампасы миңа таба үзенең рәхмәтене яудырып тора.

Мин башлыйм.

Беренче мәртәбә мин үземнең әсәремне кечкенә генә, җылы гына агач өйдә укыдым. Мин ачык бүрәнәләрнең араларына тыгылган мүкләр белә тупас сала мужигының сакалына охшаган диварлар, авызын ыржайткан сала хатынны хәтерләтә торган калҗыган ишекләре безнең өсткә карап торалар иде. Анлар, бер караганда, минем, унсигез-унтугыз яшьлек малайның, татар тормышында күрелмәгән роман язу фикереннән көлгән кеби булалар. Бер караганда, анларның шул ап-ачык тәннәрене, пәрдәсез йөзләрене күрсәткән өчен чырайларын сыталар, тешләрене ыржайталар кеби була иде. Ләкин мин ул вакытта үземнең романым белән, үземнең мөхәррирлегем белән исергәнгә, аракы, әфьюн ашаган кеше кеби түгел, башына, йөрәгенә әллә никадәр яңа исерткеч салынган кеби исергәнгә, әлбәттә, тирә-ягымдагыларны күрми идем.

Ул вакытта да хәзерге кеби өстәл төзелгән иде. Ул вакытта да хәзерге кеби самавыр кайный иде. Ләкин ул вакытта хәзерге курсисткалар, студентлар, ак сөяк хатыннар, кызлар ролендә бөтенләй башка кешеләр иде. Элгәре анларның кем икәнлекләрене сөйләп тормыйм. Берсе аның хәзер үзенең ихтиялчы «Иттихады ислам» җәмгыятенә әгъза икәнлегене жандармнарның исбат итеп бетерүләрене көтеп икенче ел төрмәдә ята. Берсе «Русиянең зур диванында «Иттихады ислам» җәмгыяте юк, бунлар ялган, ифтира», дип мөнбәргә чыгып-чыгып рус халкы алдында үз милләтене пакьләмәкче булып маташа. Берсе шәһәрдән шәһәргә күчеп, Лодзь, Варшава рецептлары берлә зур-зур тиҗарәтханәләр, кампанияләр ачып, ачылганнары җимерелгәннән, башын саклый-саклый качып, Идел буены гөрләтеп ята. Берсе Яңа бистәдән ерак түгел генә сулы җиргә салынган зур матур бакчаның иң уртасында, язгы яфрак бөреләренең исләрене иснәп, яңа килгән сыерчыкның ел буе, юл буе күргәннәрене шигырь белән сөйләгәнене тынылап, Шиһабетдин әл-Мәрҗани белән Габделкаюм әл-Насыйрига татарның хәзерге хәле хакында доклад укып, булган, булачак бөтен хәлләр вә вакыйгаларга Маркс ноктаи назарыны буяп, кычкырышып моназарә кылышып ята. Тагы берсеме? Тагы берсе Себернең мәхәббәтсез, җансыз сахраларыннан үтеп, зур гына, сасы гына, куй майлы

гына бер шәһәрдә кечкенә генә машина корып, кыргызларга, анлар аркасында кашгарларга, минем кеби язучыларның ялганнарын таратып ята.

Хатын-кыз юк иде генә түгел, ул вакытта без, хатын-кыз шундый мәҗлесләрдә була торгандыр, хатын-кыз шундый эшләргә катыша ала торгандыр, дип уйлый да белми идек, төшенә дә алмый идек. Ул вакытта Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Шакирҗан, Сабирҗан, Гайнетдин, Шәмсетдин, Гайнулла, Миңнулла, Камәруллага башка татар галәмендә бер кеше дә күрми идек, беркемне дә очратмый идек. Чапанга бөркәлгән, калфаклары күренеп китә торган хатыннарны, кызларны урамнарда, Ташаяк ярминкәсендә, бакчаларда күрсәк тә, анларның исемле-ниле, сүзле-телле, башлы икәнен күрми дә идек, белми дә идек.

Менә шунлар алдында мин үземнең әсәремне укыган идем. Ул вакытта шунлар минем хакимчеләрем булып утырганнар иде. Яратканнар идеме, юк идеме, анысы ул кадәр хәтеремдә калмаган, ләкин мин ул әсәремне китапчыга бик кыйммәт иттереп саткан идем. Шуның янына тагы бер төрекчә тәрҗемәне кушып, икесенә тулы бөтен өч тәңкәне шылтыратып алып кайткан идем.

Минем ул вакыттагы тыңлаучыларым үзгәргәне кеби, әлбәттә, мин дә үзгәргәнмен. Анларның бишесе биш якка таба киткән юлларыннан мин дә берсене аерып алганмын, яисә алтынчы юл белән бара торганмын. Ләкин шушы хәтеремдә: ул вакыттагы кеби, үземә мөхәррир иттеререп каравым һаман бетмәгән, бәлки еллар арткан саен ныгып, картаеп, шул фикер-уй минем күңелемә үзенең угыны батырганнан батыра барган.

Аңар күптән инде. Онытып та бетергәнмен, шунысы хәтердә калган, шул үземнең беренче әсәремне ике утыруда язып бетергән идем. Язган вакытта, тиле кеше кеби, вакытны-көнне сизмиче, буйдан буйга язган идем. Баштагы уй-фикер сыймаганда гына торып, җилләнеп йиңеләер өчен, идән буе йөреп-йөреп кенә бүлгәләштергән идем. Төзәтми-нитми шуны күтәреп, китапчыга чыккан идем. Аның алдында башны иеп кенә көтеп торганның соңында, аның: «Ярый, басармыз», — дигән шатлыклы хәбәрене ишеткәннең соңында, гомеремдә беренче мәртәбә әсәремне сатып, шылтыратып акча алып

кайткан идем. Аңар күптән инде, унбиш ел вакыт үткәндер. Әлбәттә, көн, ел үткән саен миңа эз калдырып, мин үзгәргәнмен. Әлбәттә, башымда тарта торган богдай да алышкандыр, башым да әйләнә-әйләнә, бәрелә-бәрелә шомарып китеп, тешсезләнгәндер, йә ныгый-ныгый җәһәннәм ташы хәленә килгәндер, анларны мин белмим, анларны тикшерү минем эшем түгел, ләкин шулсы дөрест, шул көннән бирле мин һаман язам.

Матур кояшлы көндә дә, көзге вак яңгыр ява торган, бөтен тәнне басып, йокыны китереп торган көндә дә, кышкы салкын, суык җилле буран уйнап морҗаларда ыжгырып-сызгырып үзенең ачулы көене улаганда да, маташа торгач, кояш җиңеп китеп, шул китмәскә яткан калын карларны, суның шалтырап, шомаланып агуына көнләп, аны тотып торган бозларны эреткәндә дә язам. Тагы әллә ничә кар явып, кар эрегән чакларда, әллә ничә кояш бер җиңеп, бер җиңелеп йөрүләрен дә язарга уйлап язам. Минем күнелем төшми, дәртем кайтмый, ышанычым бетми, мин язам да язам. Татар тормышы өстендә аллы-кызыллы кояш уйнаганчыга кадәр, татарның тупас, дорфа тормышы гөлле чәчәкләр, бизәкләр берлән бизәлгәнгә кадәр, татар тормышы эчендә кайный торган әчетке кабарып җитеп, татар тормышы савытының бөтен тирәсеннән ташып чыгып, Идел буйлап агып киткәнче, Урал тауларын үтеп китеп, Кашгар чикләренә барып йиткәнчегә кадәр язам. Менә тагы яздым, менә тагы язармын. Менә хәзер укыйм, менә тагы бераздан укырмын, тагы, тагы...

Тыңлаучыларга нинди хиссият калдырганыны җентекләргә вакытым юк. Мин укыйм. Тавыш юк, бүлмә тып-тын. Әллә кем генә акыртын гына намаз укучының намазыны яңылыштырмас өчен кеби генә, йомшак кына чынаягыны куя. Борынга әллә нинди яңа исле май исе бәрелә. Мин укыйм. Менә пәрдәнең ахыры. Менә бетте.

Мин күземне күтәрәм. Бөтен күзләр миңа таба карап тора. Кайсысы авыр сулый, кайсысы авыр төшле йокыдан уянган кеби, тизрәк уяныр өчен, күзләрене уйната, кайсысы каткан көенчә тора. Электрик яктысы минем күзем

берлән уйнарга тотына, күзләрем камаша. Миңа чәй ясала. Бердән эчеп җибәреп, тирә-якны карарга тотынам.

Яңа нәрсә бар кеби тоела. Күзем берлән эзләп, яңа бер кызны табам. Кыска-кыска гына сүзләрдән соң икенче пәрдәгә башлыйм.

Тагы баягы манзарә, тагы баягы тынылык, тагы күз камашуы, тагы тын алу, тагы кайнар чәй...

Өченче пәрдә, һәрьяктан авыр сулаулар, уфлар... Шунларга катышкан әллә ничә төрле исле май исе; зиярәттәге кеби, Истанбулның Әдернә капусы зиярәтендәге кеби тынылык. Менә пәрдә төшә. Бөтен тавыш бердән күтәрелә. Һәммә шунда булганнар, хәзер әйтмәсә, шул минутта әйтмәсә, онытыр кеби, сөйләргә тотына. Минем колагымда әллә нинди сүзләр чыңлый, күзем әллә нинди кул бутауларны, ирен селкенүләрне, күз ялтырауларны күрә. Һичберсене аңламыйчы, һичберсенә җавап бирмиче, көлеп, елмаеп торам.

Халык тына. Без, хәл җыяр өчен, зәңгәр залга чыгабыз. Минем каһарманнарым күз алдымда зәңгәр арестант киемнәре кияләр, зәңгәрчә сүзләр сөйли башлыйлар.

Рояль уйный. Көй, уята-уята, үзе берлән бергә әллә канларга алып китә. Тарих сахраларында гиздерә. Менә Рим падишаһлыгы, менә грекларның сугышлары, менә төрекләрнең Истанбул сугышлары, менә Сөембикәне еглашып, ялбарышып, бөтен Казан халкының озатуы. Музыка татарчага әйләнә. Татарның бер төрле көйләре, минем арган миемнең ярыкларына май сипкән кеби, хәл, көч тарата. Мин тәмам кеше. Тагы бер чынаяк чәй.

Дүртенче пәрдә. Тагы элгәреге тынылык, тагы элгәреге дикъкать, тагы уфлар, тагы авыр сулышлар. Пәрдәнең уртасында бөтен кешедә хәрәкәт. Туп-тугры бара торган трамвай кинәттән туктаган кеби, яисә уйламаганда борылып, юлыннан чыгып, тротуарга борылып, трамвайлыктан кешегәме әйләнеп, матур киенгән хатыннар-кызлар берлән көлә-көлә сөйләшеп бара башлаган кеби, әсәр дә кинәттән үз юлыннан сикереп чыгып, күк йөзендә оча башлый. Укучыга таныш Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗаннарны, Зөләйхалар, Әхмәтләрне әллә нинди канатлы, матур, пакь фәрештәләр күмә; анларның

гади, дорфа сүзләренә моң, татлы, нәзек, нечкә музыка тавышы баса. Кайгы, хәсрәт, күз яше берлән тулган суык, куркыныч уйны рәхмәт җылысы тутыра. Мин керпек астыннан гына тыңлаучыларга карыйм, һәммәсенең күзендә гаҗәпкә калу, аптырау берлән дикъкать бергә кушылган. Манзарәләр киңәя-киңәя чигенә җитә. Минем трамвай тагы эзенә төшә, тагы пәрдә гади театрдагы кеби шап итеп ябыла.

Бу пәрдәдәге үзгәрешләр, бу пәрдәдәге минем ике дөнья арасында очып йөрүләрем, минем хакымда ясалып куелган фикергә тип-тирес килгәнгә, мин җентекләп шуның тәэсирене сизмәкче, үлчәмәкче булам. Шактый озын сүзләр алыштырышамыз. Һәммәсе таң калганнар, ләкин һичберсе минем яңа юлымны, яисә яңа тәҗрибәмне тәнкыйть итми. Һичберсе: «Юк, бу җирене алып ташларга кирәк иде, фәлән», — дими. Ләкин һәммәсе әллә нәрсә әйтәсе килә, әсәрдәге шомалыкның бетүе һәммәсенең әллә кай җирене кытыклый. Башта утыртылып куелган минем сурәтем белән бүген чыккан яңа сурәтне берләштереп маташамы, әллә башлар башка уйлар берлән чуаламы, мин тегермәннәре бөтен куәте берлән тартканын сизенәм.

Иске ясап куйган сурәте яңасына охшамаганга аптырап калуга мин әллә ничә мәртәбә шаһит булганым бар. Менә бервакытны мин Истанбулга бардым. Ишеткән-белгән төрекләр, татарлар күрешә килде. Кайсы берлән аны сөйләдек, кайсы берлән башканы. Ләкин берсе һаман хәтеремнән чыкмый. Бер егет керде. Ләкин ишекне ачып кергәч тә, әллә нинди уйламаган бер эшкә кинәттән очраган кеби, катып калды. Мин аптыравының сәбәбене белмәсәм дә, икеләнүене күреп: «Боерыңыз, боерыңыз, сез мине сорыйсыз» — дидем. Теге акыртын гына: «Сез Гаяз әфәнде буласызмы?», —диде. Ләкин сөальнең әйтелүендә, авызының селкенүендә мин аның, ике төштә ике — дүрткә ышанган кеби, минем, хәзер шул алдында басып тора торган кешенең, Гаяз әфәнде түгеллегенә ышануын күрдем. Мин, көлебрәк: «Шул, боерыңыз», — дидем. Ул: «Дөньяда ниләр булмый, харикылгадә бар нәрсә инде, ахрысы, Салих пәйгамбәр таштан тәвә дә чыгарган, бу да Гаяз әфәнде булса булыр шул, ләкин ул түгел инде, нишлисең, ышанмый хәл юк», — дигән кеби генә утырды.

Сөйләштек, чәй эчтек. Бераз ачылды, ләкин күзенең төбендәге шөбһә бетмәгәнлеге күренеп торды. Аннан соң ул кеше берлән без еш-еш күрештек, таныштык. Шактый күп вакыт үткәч кенә, ул үзенең әүвәл күргәндә гаҗәпкә калуының сәбәбене аңлатты.

Ул мине әллә кайчаннан бирле ишетә икән, әллә кайчаннан бирле әсәрләремне укый, гәзитә мәкаләләремне моталәгә итә икән. Язган нәрсәләрдән битәр, сөйләнгән сүзләрдән, ул мине Мәхмүт Шәүкәт паша кадәр зур мыеклы, солдат төсле чарт-чарт басып йөри торган, калыны тавышы берлән, тирес килүне һичбер кабул итми торган көй берлән сөйли торган, биленә хәнҗәр таккан, озын кылыч кушанган, ике ягына ике зур револьвермы, пулеметмы таккан, озын, зур кәрзинәгә бомбалар тутырган, тирес килдеңме — хәзер атыпмы, бомба ташлапмы үтерә торган кеше, дип утыртып куйган икән дә, минем көлә торган йөзем, йомшак сүзем, револьверсыз-нисез гади киемем аны тәмам аяктан еккан, таң калдырган икән!

Менә бүген дә мин тыңлаучыларда шул татар күзендәге шөбһәне, аптырап калуны эзлим. Бүген дә бик күбесендә шуны табам. Ләкин сөйләшә торгач, ул шөбһә тиз языла.

Мин бишенче, актыгынчы пәрдәне шома гына укып чыгам. Без хәзер бөтен драма хакында сүзгә керешәмез. Мин тыңлап торам, анлар сөйли. Фикерләр, уйлар берләшә. Бәгъзе йирләрдә мин үземнең ноктаи назарымны күрсәтәм. Бик тиз арада һичбер бәхәс каемый, драма кузгаткан татар тормышының кара якларына күчәмез. Хәзерләнгән кичке аш мәҗлесендә сөйли-сөйли, татарларның бөтен хәлләрене актарамыз. Татар әдәбиятының роле, вазыйфасы, татар әдипләре, шагыйрьләренең өметләре, планнары хакында озын-озын сөйлимез. Бер кыз миңа: «Ник курсистка, студентлар тормышыннан язмыйсыз?» — ди. Бер абыстай зур бер тема бирә. Бер кыз: «Мин әле һаман китап берлән исергәннән базына алмыйча торам, ахырдан фикеремне әйтермен», — ди.

Мәҗлес җиңеләя, сүзләр йомшакка китә. Яхшы ашлар, яхшы эчемлекләр һәммәмезне дә шатлыклы, кәефле бер хәлгә китерә. Татарның

киләчәге хакында, Татарның киләчәк әдәбияты, музыкасы, мәктәбе, мәгарифе хакында тәмле-тәмле фаразларга күчеп китәмез. Татарның үзенә операцияне да ясыймыз, татарның үзенә махсус сәнаигы нәфисәсене дә булдырамыз. Аурупада кабул ителерлек, Аурупа мөхәррирләре берлән үлчәнерлек әдәбиятлы да ясыймыз. Матур уй, татлы фаразлар берлән сәгать үткәнне сизми дә каламыз. Доктор кыз үзенең сөякләрене, буыннарыны оныта, парахут ясаучы инженер үзенең машиналарын хәтереннән чыгара, зачет бирә торган курсистка үзенең анатомиясене оныта. Мин үземнең нелегальныйлыгымны, үземнең җиде ел бербуйдан качып йөрүемне онытам.

Һәммәмез чын тормыштан күтәреләмез, һәммәмез болытларда, күкләрдә йөримез, һәммәмез бабайларның Тәңре сайаган кояшларына таба — бай, җылы кояшларына таба очамыз.

Зур, тулы, көмеш яктысы сибеп тора торган ай безне каршы ала. Урамда тагы бер мәртәбә күрешеп, төрлемез төрле якка китәмез. Аз гына вакыт үтми: «Әй, әй, Гаяз әфәнде, без күрешмәдек ич әле, сөйли-сөйли онытканмыз», — дип ике кыз чауып киләләр. Тагы күрешәмез. Айның матур яктысын җырып-ертып килгән кызларым берлән бергә без дә китәмез.

Уртача гына суык һава. Ялтыраган ай безне котлаган кеби, безнең шул кечкенә генә татар җыелышымызга да шатланган кеби, безгә таба борыла, якты фонарене ялтыратып, юл күрсәтә.

Кызлар тагы җанлана; тагы югарыга, югарыга оча башлыйлар. Минем башка әсәрләремә күчәләр, ниләр язарга теләвемне сорыйлар. Теге зачетлы кыз, тау башларына яшел чирәм чыккач, кояшлы, матур язгы көндә саф һавага исереп, уйный, бии, сикерә торган кәҗә бәрәне кеби кылана. Ул чын күңелдән чакыруым өчен миңа рәхмәт укый. Ул тавышыннан дөрестлеге сизелә торган иттереп: «Гомеремдә бундый кызыклы, шатлыклы, мәгънәле мәҗлескә тугры килгәнем юк иде, ай рәхмәт», — ди.

Миңа да анларның шатлыгы йога, көлә-көлә кайда барганымызны сизми дә каламыз. Менә минем өйгә җитәмез. Кызлар, үземез кайтамыз, дип, мине кайтып китәргә димлиләр. Мин элгәре разый булмыйм, ахырдан төн буе

арганлык искә төшеп, мәйданга җиткәч, анларны арбага утыртып җибәрергә булам.

Менә без мәйданда. Ай ап-ак кар диңгезендә уйнап ята. Аның нурлары кар бөртекләре өстендә җем-җем итеп, биеп торалар. Дөнья кадәр зур шәһәр, айның шул бәйрәмендә башыны игән кеби, тып-тын, моң тора. Менә арбачы. Сатулашамыз, анлар утыралар. Әллә мин төп нөсхәне кызларга биримме? Юк ла, мин бит инде алты ел качып тордым, йиденчесендә килеп тотмаслар! Юк, әллә биримме? Тагы ике көннән соң укыйсы бар бит! Хәер, төзәтәсе йире юк. Ул кызлар, икенче мәртәбә булса да, икесе дә килергә булалар бит. Менә анлар күрешәләр, китәләр. Ай анларның чаналарының эзене ялтырата башлый.

Мин туктап торам. Бераздан: «Туктаңыз!» — дип кычкырам. Моң шәһәрдә тавышым яңгырап китә. Яннарына барып: «Югалтмасаңыз, нөсхә сездә торсын, алып килерсез», — дим. «Юк, юк»,—диләр. Ике кулы берлән кочаклап, Шәфика әсәрне тота. Тагы ат кузгала. Мин артларыннан: «Төшереп калдырып, югалтмаңыз», — дип кычкырам, Шәфика: «Югалсак, икемез бергә югалырмыз», — дип җавап бирә. Ай, аның шул сүзеннән көлгән кебиме, шул сүзе өчен рәхмәт укыган кебиме, нурыны мөлдерәтә. Мин өемә борылам. Соңгы төндә татлы йокыга чумам.

***

Челтәрле пәрдә аша үтә торган кояш нуры, әллә кайчаннан бирле төрле-төрле бизәкле шәүләләр ясап уйнаса да, мин ялкауланам, иркәләнәм, эвәләнәм. Кабыргалар арасыннан үтә торган йомшак җылысыннан тагы озаграк ләззәтләнер өчен, анасы куенында йоклый торган бала кеби, бер яктан бер якка әйләнәм, аякларымны сузам, җыерам, зур бер сәгадәтне кулдан ычкындырмаска теләгән кеби, тормыйм. Ник соң рәхәтләнмәскә? Рәхәтләнергә мөмкин булса, теләгәнчә рәхәтлән, җае килгәндә, һичбер минутны, һичбер форсатны әрәм итмә! Тагы минем урын торырлыкмыни? Астта йомшак, акыртын гына сыгыла-киерелә торган көрпә. Аның өстендә, ак кар кеби, җем-җем итеп тора торган түшәк япмасы. Баш очында Идел буе

казының кыйгылдап-кыйгылдап, җәйләр буе җыеп, киләсе елга йомыркасыны җылытып, бәпкәләрене суыктан сакларга хәзерләгән ак мамыгы. Өстемдә Әлҗәзаирның, Тунисның ерак Сәхраларының эчендә, ком диңгезенең уртасында, бер төркем чәчәк төсле яшәреп, матураеп утыра торган хөрмә бакчаларыннан татлы, тулы, күргәндә авыздан сулар агыза торган хөрмәләрне ташый торган тәвәләрнең мамыгыннан ясалган француз юрганы!.. Аның арканы ничек җылытканын белсәңез иде, аның җилкәнең иң ачык кала торган җирләрене ничек томалап, каплап, Африка уртасында җыйган җылысын җәйгәнене татысаңыз иде — ант итсәм дә, ханис булмыйм — сез дә шул юрганнан башка юрган алмас идеңез, сез дә, минем кеби, торырга ашыкмас идеңез.

Кояш уйный да уйный. Мин һаман тормыйм. Ник торыйм? Минем ни эшем бар? Әсәрме? Әсәр язылып кына бетте түгел, өч-дүрт мәртәбә төзәтелеп тә бетте! Кичә кич берлән укып чыктым. Ул хәзер, минем җилкәмә әллә ничә еллар асылып йөрелгән йөк кеби, бүген тәмам төште. Ул бетте, тәмам бетте. Һич бетмәс дип уйлаган, һич очына чыга алмам, дип кистергән әсәр бетте. Чын да беттемени? Һич ышанмый идем, бу бәхетсез татарның бәхетсез тормышын күрсәтә торган әсәрнең болай тәмам булуына ышанмый идем.

Мин инде бу әсәрне әллә кайчаннан бирле бит, муеныма тагып, өстерәп йөрим, шул йөк берлән берничә мәртәбә төрмәнең тимер челтәрле ишегеннән үттем, шул йөк берлән мин Архангельның суык сахрасыны кичтем, йөкне һаман ташлый алмадым, әманәтне иясенә ирештерә алмадым.

Беренче мәртәбә мин аны Чистай төрмәсендә язарга тотындым. Бер-ике утырып язгач та, безнең бүлмәдә тентү ясадылар, минем язган әсәремне алдылар. «Татарча язарга ярамый», дип әмер бирделәр, әсәр дә югалды, дәрт тә кайтты. Аннан соң төрмәдән чыккач, хәлләр бераз иркенәйгәч, үземә язу өстәле алгач, мин сызыклы кәгазь алып, өч кырлы каләм табып тагы язарга тотындым. Шактый яздым. Бер пәрдәне бетердем. Икенченең ахырына җиттем. Минем шул әсәрне яза башлаганымны Петербургтамы, Берлиндамы, белмим кайдадыр, белделәр. Мине тагы төрмәгә алып киттеләр, минем берлән

бергә әсәремне дә алдылар. Әлбәттә, прашение бирдем, кайтарыңыз, биренез, дип сорадым. Кайтмады...

Сулар акты, еллар үтте. Мин елгалары башка тарафка ага торган, җилләре башка яктан исә торган, кояшлары гөл үстерә, йөзем пешерә торган, сандугачның сайравыны тыңлап, сәрве агачының манаралар белән узышып үскән очларыннан мәхәббәтләрене, сөешүләреен күккә таба җибәреп тора торган, ике сөюченең серләрен сизәр өчен, анларның авызга авыз куйганнарын күрер өчен, елмаеп-елмаеп хофиялек итә торган халыкның йиренә күчтем.

Бер тәрәзәмнән бугазның иң матур боргаланган йирләре, чинар, сәрве, кедра, юкә агачлары белән хәтфәләнгән таулары арасыннан солтан Фатыйхның кальгасы зур күзләрене ачып, тарих бәбәге белән карап тора торган, бер тәрәзәмнән Истанбулның озын манаралары, баскыч-баскыч иттереп, күккә чыгарга теләгән кеби ясалган урамнары, Истанбулның шул зурлыгына, мәһабәтлегенә хәйран булып, башыны иеп тора торган Мәрмәрә диңгезе карый торган бүлмәдә Икенче Мәхмүтнең кызы, юкә агачыннан шома булып, юкә чәчәгеннән хуш исле булып үссен, дип ясаган юкә бакчасы чәчәк атканда өченче мәртәбә башладым. Иске татар халкының иң урта йирендә, бәхетсез татар хатынының вөжданына, диненә, гадәтенә каршы ителгән шул җинаятьне, якыннарыңны сөю идеясе белән капланган Аурупаның уртасында кылынган шул вәхшилекне, Кара диңгезнең ачы суында юып, Малорусиянең киң сахрасыңда ачыларыны-төчеләрене җилгә очырып, Кандилленең аллы-гөлле һавасында гөл исенә буяп, юкә исеңдә сөзеп, авыр исене, авыр хиссиятене җиңеләйтеп, кәгазьгә чыгарырга уйладым. Артык-портык аурупалык фикерләрене, азиялык уйларыны төрле яктан килә торган җил белән суырып ташлап, ачык күз, ачык уй, хөр баш белән язар өчен, Аурупага карап тора торган Азиянең шул биек тавын иң мәслихәт йир таптым. Сәяси җәһәттән хөрлек, язган бер кәгазеңне кайчан алалар, дип куркып торуның юклыгы да бик аз роль уйнамады.

Бер пәрдә, ике пәрдә, өч пәрдә яздым. Уем белән Истанбулда язып бетерергә кистергәнгә, дүртенчегә тотындым. Мин аурупалы бер мәмләкәтнең

тәмам аурупача идарәсеннән качып, кунак булып килгән хуҗаларымда зур кәефсезлек башланды.

Әлеге якыннарны сөю исеменә Аурупаның кулын селки, аягын бутый, сорнай тарта, сикерә, бии торган бер җилбәзәк угылы, көзге караңгы төндә, искәртмәстән минем өй хуҗаларымның хөрмә бакчаларына кереп, урларга тотынды. Урлый, талый картаеп беткән аның зур агалары теше арасына зур челемен кабып, кайберсе, кулындагы зур бокал сырасын эчкәч, тамак ялгар өчен кесәсендә йөртә торган пөйнирене чәйнәп, кайберсе куркаклыгыны, көчсезлегене яшерер өчен, бик көчле кешеләр кычкыра торган сүзләрне кычкырып, кулын чабып, шул шпананың эшене тамашага тотынды. Трубкалысының чыраены сытыбрак, сыралысының көлебрәк, тегесенең ватык тегермән кеби гөрләп, шул караклыкны күтәрешүләре хуҗаларымның тәмам кәефен җибәрде. Анларның иске Азиядән алып килгән һавалыкларыны, бабайлардан бирле угылдан кызга күчеп килгән тугрылыкларыны мыскыл итте. Урам халык белән тулды. Мөхәррир каләмене, рәссам пумаласыны, сатучы аршиныны, шәкерт дәресене, мулла тәсбихене ташлады. Халык диңгезе нишләргә белмичә, урамнан урамга ага, бәрелә, әллә ни көтә башлады. Яшьнең, картның уе-фикере шул бакчага, шул сикерә торган шпанага таба борылды. Тормыш иске юлыннан чыкты.

Мин дә шул уй-фикер дулкынына чыдый алмадым. Урынымнан куптым. Каләмне ыргыттым. Урамга чыктым. Күп үттеме, аз үттеме, белмим, ләкин шуннан соң мин язарга тотына алмадым. Уйлаштым, сөйләштем, ни өчендер, яңадан үземнең мәмләкәтемә, үземнең үги анама кайтырга уйладым.

Ноябрьнең соңгы моңлы җылысында йөзем, инжир исе мине озатып калды. Сулар кичтем, сахралар үттем,торачак шәһәремә килеп йиттем. Урамнан ага торган саз, күктән ява торган былчырак белән берләшеп, мине каршы алды. Киң урамнарда хезмәтче кыз төсле киенгән курсисткаsuccessful, курсистка төсле киенгән фахишәне, бәрәңге борынылы бай-ярлы хатыннарны, кып-кызыл борынылы ирләрне үтеп-үтеп, үземнең кечкенә генә татар ояма килеп кердем. Кәгазьләрне-фәләннәрне яшереп, көн дә бүген киләләр, бүген

киләләр, дип көтеп арып беткәннең соңында, тынычлап, тагы язарга керештем. Дүртенче пәрдәне бетердем. Бишенчегә күчтем. Аны да бетердем. Бер мәртәбә, өч мәртәбә, дүрт мәртәбә төзәттем. Инде укып чыктым. Әйе, инде эш бетте. Инде килүләреннән курыкмыйм. Хәер, куркам. Бер генә нөсхә бит, алсалар, әрәм була.

Чын да шулай бит әле; төп нөсхәне Шәфикагә бирдем. Ул югалтмас. «Юк, юк, югалмас, югалсак, бергә югалырмыз», — диде. Бергә югалмаслармы? Юк, мин бетердем, мин зур йөкне өстән төшердем. Мин хәзер хөр генә түгел, сугыштан кайткан гаскәр кеби, хәл җыярга хакым бар. Тагы урында әйләнәм. Ишекне шакыйлар. «Самавыр күптән кайный, менә гәзитә», ди. Торырга кирәк, торырга.

Торам, юынам. Иртә белән талгын су белән юыну никадәр рәхәт биргәнне беләмсез? Юктыр. Минем кеби, бабадан бабага [күчеп], көненә кырык юынырга гадәтләнмәгән булсаныз, аңламый торгансыздыр. Әмма мин юынуның тәмене беләм. Юынам да иңде! Истанбул кеби суның кыйбатлы йирендә шуның өчен мин хуҗа хатыннардан орышу да, шелтә дә алам, ләкин юынам. Бик тәмле иттереп юындым. Самавыр да керде. Бер кулга гәзитәне тотып, бер кулга стаканны тотып чәй дә эчтем. Бар да тәмам.

Бүген нишләргә? Хәзер Истанбулга китә торган бер танышларга барырга кирәк тә, кайдан китүләрене белешергә кирәк. Анда ашап-эчәм. Аннан кайтып, хәзерләнеп, кичкә театрга китәм. Күптән бирле «Ревизорны» күргәнем юк. Билет алырга дип әллә ничә бардым, тугры китерә алмадым. Бүген алдан барып, барышниклардан алам. Киенәм, Истанбулдан алып кайткан яңа костюмны киям. Зәңгәр сыман йирлек өстендә күренер-күренмәс кенә юллар сузылып тора. Анлар, чалбар тез турысында бөгелмәс өчен, пинжәк кирәкмәс йирендә генә җыерылмас өчен яшереп куелган нечкә ефәк чыбыклар кеби, кояш, электрик яктысында киерелеп, туң гына ялтырап торалар. Алдыңдагы ачыкта ап-ак күкрәкнең таза, нык, киң, гырламый торган икәнене күрсәтеп тора, тегүе дә тегү түгел, койган да куйган! Печемене Идрис пәйгамбәр печкән, тегүене оҗмахта хөлләләр тегеп тора торган фәрештә

теккән якалар, куллыклар да җете ак, алар үзләренең аклыклары белән минем кара чәчемне тагы каралталар, аның яшеренеп-яшеренеп кенә чыга торган ак бөртекләрене, үзләренең аклыклары белән оялтып, тагы эчкәрәк яшертәләр. Минем пальтә дә костюмнан ким түгел. Аның һаваланып, сорыланып тора торган җирлеге әллә никадәр вәкарь бирә, аның сылаган кеби тегелүе әллә никадәр пөхтәлек бирә, аның арт ягында озын иттереп ерылган ерыгы кибарлек бирә. Котелок та соңгы калыпта, һәммәсе йирле җирендә. Мин көзгегә карыйм! Мин хәзер көпе киеп йөргән бабайларга, җилән, чикмән киеп йөри торган этиләргә аз гына охшаганмын. Мин тәмам Аурупа кешесе, төрекчә әйтсәң, аурупалы әфәндем. Шул көпеле бабай, мине күрсә, хәзер ни әйтер иде, Урал суын үткәндә кымыз тузагына салып, ат койрыгына тагып, өстерәтеп чыгарган угылы икәнене таныр идеме? Кулыны селкеп: «Юк, түгел, түгел, минем бундый угылым юк иде», — дип кайтып китмәс идеме? Китәр иде, ләкин тагы бераз киткәч тә борылып карап: «Мин, түгел, дим дә, шуңар охшый, күзе-башы минеке, аяк басулары, көлүләре әбисенә охшаган, шул курчак киеме генә картайган күзләремне алдый түгелме? Тукта, карап карыйк».

— Әссәламегаләйкүм, энекәш!

— Вәгаләйкемәссәлам, бабай!

— Мин сине әллә кем, ят йирлек дип торам, син мине куркыттың! Кием урынына әллә нинди нәрсәләр эләктергәнсең, шунлар белән урамга чыгарга оят түгелмени?

Кулы белән киемнәрне тотып карап:

— Кара, кара, нәрсәсе шома гына, алай да таза булмаска кирәк, черектер. Менә әбиең суккан тула башка була, буявыны әйтә алмыйм, синеке матуррактыр, кияүләр кия торган кытат төсле. Ныклыгы, тазалыгы кая ул безнекенә җитәргә, ник бик тар, буның кай төшендә җылы торсын? Бүркең бөтенләй карга оясы, әй, колакчаны да юк түгелме? Колагыңны алдырырсың дип курыкмыйсыңмыни? Сез яшь әле, сездә әле кан кайный! Менә мин картайдым, җәй көнендә җилән өстеннән толыпны кими йөри алмыйм.

Бишмәтен начар түгел, әйбере шактый җуан. Йоннанмы? Бу да өйдә сугылганга охшамый. Ай, бунда бик зур ертыгы бар лабаса! Өр-яңа түгелме соң? Ертып та өлгергәнсең, ай бала, карап йөрергә кирәк!

— Юк, бабай, ул ертык түгел, тегелүе шулай, модасы шундый.

— Ә, алай диең. Ник бик тар, бунның кай төшене өстеңә киясең, кай төшене ябынасың? Аякка сузсаң — башка юк, башны өртсәң — тезгә юк, арканы капласаң — күкрәк ачыла, күкрәкне томаласаң — җилкә тышта кала. Менә әбиеңнең бишмәте нигә дә ярый, өсткә дә рәхәтләнеп киеп йөрисең, ике яклап каршы китереп билбаулагач, ике чабу бергә килеп тезгә җылы була, өсткә ябынсаң, башка да җитә, аякны да өртә, аркага да, җилкәгә дә җылысыны кызганмый, искерә төшсә, әбиең килен-килмешкә шуннан юрган ясый, дүрт почмаклы булып йитмәсә дә, синең дүрт почмаклы юрганыңнан җылы була. Аңда да тузса, ике чабуын аерып, балага-чагага ябынрга бер-ике юрган чыгара. Жиңеннән-фәләненнән бишеккә салырга көрпә хәзерли. Бу, тузса, нигә ярый? Чабудан чабуы юк, буйдан буе.

— Бу шул, бабай, кияр өчен генә, ябыныр өчен түгел.

— Дөньяның, угылым, төрле хәле була. Киярсең дә, ябынырсың да. Ярый инде, сез яңа кешеләр... Йә, ниләр бар, мал-туар исәнме?

— Минем, бабай, мал-туар юк.

— Синең мал-туар юк? Соң син кымыз урынына нәрсә эчәсең, ит урынына ни ашыйсын? Илгә-көнгә нәрсә атланып чыгасың? Сабан туенда, катыксыз, кунакларыңны ни берлә сыйлыйсың? Әллә инде сездә кунак хөрмәте беттеме?

— Юк, бабай, әлхәмделиллаһ, искечә. Без хәзер чәй эчәмез, корт-катык урынына пәйнир ашыймыз, элгәреге кинлек бетте инде, бабай.

— Күрәм, күрәм, элгәреге иркенлек булса иде, киң сахрада үскән малай, син, шул бүлмәдә кысылып тормас идең, шул тар киемнәрне киенеп, кысылып-пысылып йөрмәс идең! Соң инде мал-туар юк дисең, ни берлә көн үткәрәсең?

— Мин, бабай, язам.

— Ә, язасын, яхшы эш, безнең заманда язучылар хан сараенда урын тоталар иде. Мин берсене беләм, урыс кенәзенә ярлыкмы булсын, поляк падишаһына әмерме булсын, фарсы шаһына фәрманмы булсын һәммәсе аның кулыннан үтә иде. Син дә шулай инде. Бик матур яза, диләр иде.

— Юк, бабай, мин бик ямьсез язам, мин язганнарны типографиядә танымыйча эштән чыгалар.

— Алай булгач, сине яман чиремәмени тоталар? Син соң, ямьсез язгач, нишлисең?

— Мин, бабай, әкиятләр язам. Сезнең заманнарда ниләр булган, хәзер ниләр була, шунларны язам.

— Ә, аңладым, аңладым. Безнең заманда анларны язучы бар идеме, юк идеме, белмим. Ләкин сөйләүче күп иде. Безнең күрше өч хан гомерендә сугышка йөргән, Мәскәүдән, Киевтан егермедән артык кыз китергән, Кырбатыр бар иде, гомере буенча кырык ике сугышта булган, тәнендәге сөяге кадәр үк җәрәхәт алган, тәнендәге тамырларының саны кадәр кылыч-хәнҗәр ярасы күргән. Менә картлыгында йиде падишаһның йирендә йөргәндә күргәннәрене, ишеткәннәрене сөйли иде. Бу юлы ябылгач, сахра карлы су белән тулгач, ай төрле моңлы күзе белән карап торганда, ачылып килә торган чирәмгә утырып, Зөһрә йолдызы төшлеккә йиткәнчегә кадәр сөйли иде. Син дә шуның кеби икәнсең, синен күргәнең, белгәнең, белмим, күптерме, син бит бик яшь күренәсең. Ничә падишаһның тәхетене корганда сугышта булдың? Ничә мәмләкәтне ачканда үлем ярасы алып терелдең?

— Юк, бабай, бер сугышта да булмадым. Хәзер бит тәхетләрнең нигезләре ныграк корылган, мәмләкәтләрнең чикләре башкача беркетелгән.

— Алай булса, мин сине аңламыйм, мин менә шуннан, Кырбатыр бабайдан ишеткән хикәяләрне бер сөйлим, тамак бетсә дә аннан ишеткән җырларны җырлыйм дигән идем, син әллә кая барырга киенгәнсең' Башка вакыт килермен. Әллә син инде ул көйләрне оныткансың да, синең көең дә киемең төсле кыска, шуның төсле киртекле-портыклыдыр. Йирең дә бүлмәң кеби тардыр. Хуш, әлегә.

— Юк, юк, бабай, рәхим ит, бик шат булырмын. Мин бабайның прастуйлыгыннан көлә-көлә аерылдым. Петербургта бик сирәк була торган нурлы кояш мине баштан аягыма кадәр рәхмәтендә коендыра. Акрын гына атлап, күкрәкне киереп сулап, алга таба барам. Менә мин хәзер мәйданда. Әнә шунда кичә теге әсәрне биреп йибәрдем. Бәлки юкка бирдем. Карасана кояшны! Бигрәк матур. Мин нинди бәхетле! Ничек рәхәтләнеп кояшлы көндә үзем теләгәндә чыгып, кая теләсәм шунда барып йөрим. Бигрәк рәхәт, бигрәк бәхетле. Кояшы да юри мин чыкканны көтеп торганмыни! Нинди йомшак кыздыра! Бу рәхәтне тиз генә кулдан ычкындырырга ярамый! Мин кояшлы яктан бөтен Невский буйлап җәяү барам. Менә иркенлек рәхәтлеге! Төрмәдә булсаң, болай рәхәтләнә алыр идеңмени? Бу кояшта коена алыр идеңмени? Мин иректә, мин кояшта. Жуан дивар миннән кояшны аермый, тимер челтәр үзенең дорфалыгында аның нурыны сындырып, шул рәхмәткә үзенең ямьсез-легене бутый алмый! Кояш мине күтәрә, кояш мине киерә, мин шатлык, рәхәт белән тулам. Менә тагы урам. Борылам. Кыска гына шәүләле йирне тиз-тиз атлап үтәм. Тагы кояшта, тагы рәхмәт диңгезендә. Менә әллә кем минем исемем белән кычкыра! Кем икән? Борылып карыйм, бер дә таныш кеше күрмим. Тагы үземнең шатлыгыма чумып алга атлыйм. Менә әллә кем каты кулы белән арт яктан җилкәмнән кысып тота. Кояш рәхәтендә йөзеп барганда, кинәттән булган шул каты дорфа хәрәкәт мине аптыратып җибәрә. Күземне ачып карасам, кырган сакаллы, сары мыеклы, үлгән сарык күзле, чырайсыз бер сыщик күзене акайтып тора. Аның янында тагы берсе, күз ачып, күз йомганчы ике кулымнан тоталар. Мин айныганчы, әллә кайдан килгән чанага да утырталар. Мин: «Ни бар? Ни булды?» — дип сорарга өлгерә алмыйм, тюк ташлаган кеби, мине чанага салып, икесе ике кулымны тотып, өстемә менеп утыралар. Ат кузгала, әллә нинди йортка борылып та керәмез. Мине тагы бик акрын гына, ватылудан курыккан кеби генә төшереп, бер ишеккә таба боралар. Диварлар, морҗалар арасыннан сыгыла-бөгелә үтә торган кояшның нуры мине озатып кала. Караңгы коридор. Минем йөрәгем тибәргә тотына. Кая алып баралар? Кыйнаргамы? Түгелме? Менә атлыймыз, мин дә һәр секундта майлы

русча сүзләр белән башка сугып җибәрүне көтәм, атлыйм, тагы атлыйм, һаман сукмыйлар. Менә дөм караңгы, шунда кыйный торганнардыр. Мин шул көтүдән тизрәк котылыр өчен шул «хәзер сугалар, сугалар» уе башта уйнап куркытып тормыйчы, фигьлияткә чыксын өчен адымны акрынылатам. Секундлар үтә, сеңерләрем киерелә, куркуымның чигенә йитәм. Һаман кыйнамыйлар да кыйнамыйлар. Ишек ачыла, без полициядә. Ике сыщик кулны йибәрми тотып торалар. Городовой, яңа бер сыщик кесәләремдә, киемнәремдә актарына башлый. Вак-төяк кәгазьләр белән ике почта квитанциясе чыга. Тагы бер кесәгә керәләр — бер адрес чыга, мин ул адресны күргәч, кызарып-бүртенеп китәм. Һич уйламаган адрес, уйланмыйча кесәгә тыгылган да, онытылып буңарча калган. Протокол. Мин азрак сулыш алам. Җуан, дорфа околоточныйдан ник тотканнарын сорыйм. «Белмим, белмим», — ди.

— Исемең кем? Фамилияң ничек?

Мин үземнең ялган исемемне, ялган фамилиямне әйтәм. Бәлки бер-бер яңлышлык бардыр, ычкынып булмасмы?.. Ике сыщик бер-берсенә карап елмаешалар. Мин берсенең карточка дигәнене ишетәм. Димәк, бунлар минем кем икәнемне белеп тотканнар. Язалар, сызалар, полициягә әллә кемнәр килә, керә, чыга. Мин: «Йә, мине нишлисез?» — дим, околоточный: «Охранный отделениягә йибәрәмез», — ди. Мин эшне аңлыйм. Нишлисең! Бәлки урамда барганда халык күп булыр, ычкынырга мөмкин булыр, бәлки шунда утырганда искәртмәстән чыгып китеп булыр!.. Шунларны уйлап, күз алдымда үткән бормалы-бормалы коридорны төшәм, ишекне һич таба алмыйм. Чынлабрак белешер өчен тышка чыгарга сорыйм, чыгаралар. Ишектән карыйм, тагы очына чыгар хәл юк. Околоточный мине чыгарган городовойга: «Строгий надзор!» — дип кычкыра. Тагы керәм. Бүлмәдә тагы бер городовой белмәгән булып кына яныма утыра. Язу бетә, минем кәгаземне городовойга биреп, мине озаталар. Тагы якты кояш каршы ала. Урам буйларында сыщиклар йөреп тора. Мине ник тоттылар, иске сөрелүне бетерер өчен генәме? Әллә бер-бер яңа эш чыгармакчы булалармы? Нинди яңа эш?.. Анларга барыбер түгелмени?

Ниндине дә ясап була бит! Бөтен эш үзләре кулында. Хәзер, миннән башка минем өемдә, баягы бабай берлә сөйләшеп утырган өемдә тентү ясап яталар. Белмим, нәрсәләр табарлар. Белмим, язган әсәрләремнән нинди мәгънәләр чыгарырлар. Юк, Невскийга чыккач качуны уйларга кирәк!

Чыгамыз, урамда былчырак себерә торган ике дворник, почмакта басып тора торган бер городовойга башка беркем дә юк. Бу ни бу? Халык кая? Бәлки Сарай мәйданында күбрәк очрар. Анда да япа-ялгыз. Менә Невага таба барамыз. Әллә күпергә таба борылырмыз. Йөге, арбачысы, кешесе күп булыр да... Юк, Нева аша җәяү чыкмакчы була. Тугры гына юлдан, бездән алда өч-дүрт кеше чыгып бара. Каршы яктан сирәк-сирәк, тезелеп кенә ун-унбиш кеше килә. Бөтен тирә-як ачык, кая китсәң дә яшеренерлек һич урын юк. Бәлки теге якка чыккач? Менә каршы яктан бер татар егете килә. Чү, шуңар әйтим: минем танышларга, дуст-ишләргә кереп, минем тотылганымны әйтсен. Арттан килә торган кеше сыщик булса да, бу татар егетене тотып алып, мин әйтергә кушкан кешенең башын әйләндерсәләр, тентүләр ясасалар, нишләрсең?! Алла сакласын. Юк, кирәкми. Әллә әйтимме? Юк, ярамый. Каш ясыйм дип күз чыгармыйм. Менә Неваны үттек. Су буйлап, урам буйлап халык йөри. Һәммәсенә дә тугры, тугры карыйм, бар да сыщик. Капка ачыла, охранкага керәмез. Менә зур гына приемный, иске карт сыщик чәй эчеп утыра. Околоточный кеби берсе әллә нәрсә язып тора. Мине китергән городовой кәгазьне бирә. Теге укый-укый да миңа карый. Ишекләр ябыла, ишекләр ачыла, керәләр, чыгалар. Әллә ни сөйләгән булалар, миңа карыйлар-карыйлар да чыгалар. Менә тагы берсе керә. Мине чакырып алып чыга. Кая?.. Йортка чыгамыз, баскычка менәмез, әллә нинди караңгы гына коридорга керәмез. Ачкычлы бер городовой каршы ала. Зур гына, тузанлы гына, суык кына бер бүлмәгә мине кертәләр. Мин, менә шунда инде кыйнау башлана, дип көтеп торам. Тагы кереп кыйный башламыйлар, мин үзләшеп китәм, бүлмәне карарга тотынам. Кара клеенкалы кәнәфи, табуретка, өстәл белән бөтен җиһаз тәмам. Кәнәфигә утырып уйлыйм: нишләргә? Фамилияне ачаргамы?.. Ни

булыр әле, нишләрләр, бердән, Архангельга җибәрәләр кеби тоела, бердән әллә ниләр казып, әллә кайларга, төрмәдән төрмәгә күчерәләр кеби сизелә.

Күз алдымда әүвәлге тотылуым, стражниклар, төрмәнең надзирательләре, анларның ыржайган авызлары килеп баса! Аның артыннан бергә утырган төрмә иптәшләре берсе артыннан берсе, ерак сандыкта сакланган нәрсә кеби, торып-торып чыгалар. Менә минем беренче тотылуым, менә кулын миңа бутап-бутап, «сугып йибәрәм, сугып җибәрәм», дип тора торган околоточный. Менә почмаклары параша хезмәтене дә итә торган һавасыз, юеш караңгы бүлмә. Аңар күптән инде. Мин, кояшның урамнар, өйләр берлә күрешеп кала торган яктыларын җибәргән чагында, бер зур шәһәрнең сасы урамы аша матбагага таба борылам. Бер-ике көн бер-буйдан язылган мәкаләләремне, кулымнан үткән хатлар, фельетоннарны актык мәртәбә күздән кичермәкче булам. Белер хәл юк, хәреф җыючылар ниләр җыеп бетермәгәннәрдер. Төзәтүче минем, кытай язуларымнан нинди мәгънәләр чыгармагандыр. Йиңелгә сайарга ярамый. Партиянең мәсләкләренә мохалиф, үземнең әхлак кагыйдәләремә тирес әллә нинди җөмләләр ычкынып китсә, нишләрсең! Безнең татар кеби, әхлак, мәсләк боламык кеби сузылып яткан халыкта фикер, мәсләк яшь илнең балы кеби саф, пакь көенчә бирелергә кирәк. Таркау тормышта талкан кеби тузыныкы әхлакка өйрәнгән яшь укучыларны, баш бөкмичә, тәрилкәләнмиче, сәнҗагыны туп-тугры күтәреп йөрергә өйрәтергә кирәк. Бу бик әһәмиятле. Шуның өчен мин һәрнәрсә хакында ни уйлыйм, шуны сөйлим.

Татарның дөньясына чыккан һәр мәсьәлә хакында үзем дөрест дип уйлаган фикеремне курыкмыйчы кычкырып игълан итәм. Шуның өчен үземне үзем бик нык тикшерү астында тотып, һәр эшем, фигылем, уемны мәгълүм мәсләк ноктаи назарыннан, мәгълүм әхлак кагыйдәләре күз карашыннан сөзәм. Шунларга хилаф бербер нәрсә булмасын өчен хәзер дә матбагага барам. Урам тулы халык. Менә ун-унбиш приказчик, пөхтә генә киенгән өстләренә үзләре дә кызыгып, кибет ябып кайтып киләләр. Кулына чапанын тоткан бер хатын, тирә-ягына карана-карана, ире талчуктан кайтып кергәнче өйдә булыр

өчен трамвайга өлгерергә маташа. Жуан битле, кечкенә күзле итчеләр акыртын гына гәүдәләрене бер йирдән икенче җиргә күтәреп куеп, кибетләр ябып азапланалар. Урамны үтәм. Тугрыга кисеп, икенче бер тар урамга кермәкче булам. Каршымнан бер кулына әллә нинди иске-москы хатын-кыз әйбере тоткан бер рус егете белән, аның кулыннан тоткан бер городовой килә. Мин күземне бер-ике сөзеп алып, юлыма китәм. Менә чатта тагы бер городовой тора. Үземнең куркып йөрмәгәнемне белдерер өчен аның күз алдыннан ук үтеп китәм. Мин инде сигез ай качып йөргәнгә, городовой күргәч тә тамырларым тибәргә тотынмый. Юри анлар яныннан үтәм. Сәгать-фәлән, урам-фәлән сорыйм. Буннан да әнә бер кибет янына җыелган халыкның җыелуының сәбәбене сорап китәм. Биш-ун адым атламыйм: «Тукта, тукта!» — дигән тавыш ишетәм. Әйләнеп карасам, артымнан городовой килгәнне күрәм. Ул мине бик тиз килеп тотып: «Әйдә полициягә»,—ди.

— Ни бар? Ни булды?!

Ул мине тарткалый, төрткәли: «Әйдә, әйдә! Күп сөйләмә!» — ди. Мин кычкырышырга, сугышырга тотынам. Тагы берсе килә, тагы берсе... Мине тотып алалар да, баягы урамда күргән сәләмә юбкалар күтәргән рус егете янына китереп кушалар. Городовой егеттән: «Шулмы?» — дип сорый. Теге рус егете:

— Шул, — дип җавап бирә.

— Нәрсә шул?

— Менә шул юбкаларны мин синнән сатып алдым.

— Миннән сатып алдың?..

Мин аптырап калдым. Городовой белән чынлап аңлашмакчы булам, булмый. Аның ахмаклыгы, тупаслыгы ачуымны китерә. Мин аның кулына утыз-кырык тиен төртеп китү урынына, аның берлә талашырга керешәм. Менә полициядә. Анда городовой:

— Мин үз күзем берлә күрдем, менә бу егет буннан (миннән) сатып алды, — ди.

Мин аптырап калдым. Зур гәүдәле, тупас битле, балта берлә генә ясап, ярар әле шунда, Русия киң, бер йирне тутырыр әле, дигән кеби чырайлы околоточный кычкыра, сикерә, кулларын бутый. Мин:

— Тукта, тукта, кызуланма, — дип үземчә эшне аңлатырга тотындым. Ул туктамады, ишеттермәде, сүгенде, акырды, бакырды. Минем адресымны сорап, тентү җибәрергә кушты. Тентү сүзе мине куркытканга, мин тагы эшне аңлатмакчы булдым. Бит минем өемдә, кем белсен, ниләр бар! Мин бит зур бер гәзитәнең баш мөхәррире, һәм дә кып-кызыл гәзитәнең мөхәррире! Файда бирмәде, әллә кайдан тагы берсе чыкты. Аның каны суыктырмы, әллә йокысын туйдырып, хәзер генә чәй эчеп, кәефләнеп килгәндерме? Минем сүземне тыңлады. Сүз арасындагы карак авызына, юбка урлый торган карак авызына керми торган әдәби җөмләләрем аның күңелендә шөбһә уяндырды. Ул теге карактан ничек булды, дип сорарга тотынды. Теге каушады, какшады, әллә ниләр бутап бетерде. Ахырдан миннән өч тәңкәгә сатып алдым, диде. Околоточный: «Нинди акчалар бирдең?» — диюенә, «бер өчлек», — диде.

Околоточный миңа:

— Синең акчаң бармы?

— Бар.

— Күпме?

— Утыз тәңкә.

— Ниндиләр?

— Өч унлык!

Тентү керә. Бер минутта тентеделәр. Кесәмдә өч унлыктан башка өч-дүрт тиен акча чыкты. Минем эш тәмам ачылды. Теге карак: «Бәлки бу түгелдер, шуның төсле иде». — диде.

Теге околоточный каракка җикеренде, җикеренде. Мине чыгарып җибәрергә теләде. Ләкин баягысы: «Тентү китте», — диде. Тентү кайтканчы мине иптәш карагым берлә бергә түбән катка төшерделәр. Эңгер-меңгер чагы булганга, күрер-күрмәс икешәр баскычны берьюлы атлап, түбән төштек. Городовой әллә нинди бер ишекне шалтыратып ачты. Аннан сасы тәһарәтханә

исенә юеш ис катышып борынга бәрелде. Мин, аптырап, аякларым атламый башлады. Городовой: «Нәрсә торасың?» — дип төртеп кертеп җибәрде. Куе караңгы мине йотты. Юеш сасы ис албасты пәрие кеби басты. Мин аптырап, атларга да, кая таба селкенергә дә белмичә, торган йиремдә катып калдым. Күземнең бөтен көчене җыеп, шул караңгылыкны ертырга керештем. Еракта гына кечкенә түндәк кеби бер нәрсәнең шәүләләнүене аердым. Сасы юеш шунда таба куды. Бер атладым, ике атладым. Әллә нинди йомшак, лебердәп тора торган нәрсәгә бастым. Борынга әллә нинди яңа бер ис керде. Кызу-кызу атладым. Аяк берлә шап итеп җанлы бер нәрсәгә бәрелдем. Мин туктап өлгермәдем, җанлы нәрсә селкенде, тиберченде. Карылган тамагы, яшел тавышы берлә, мөәззин камәт төшергән кеби, аналы-әбиле матур рус сүзләрене коярга тотынды. Әллә кайдан бер тавыш: «Анда исерек бар, бундарак!», — диде. Тәрәзәгә таба бардым, суламакчы булдым. Тәрәзәне ачмакчы булдым, ачылмады. Теге тавыш тагы:

— Сез кемнәр? Кыйнадыларммы? — диде. Минем иптәшнең: «Юк», — дигән сүзенә:

— Алай булса, әзрәктән кыйнарлар. Чукынган, теге сары мыеклы городовой бик усал, эчкә тибә, — диде. Мин сүзгә катышмадым. Минем иптәш тегеңәр хәлне аңлатты. Теге минем хакта:

— Бу кем соң? — диде. Минем иптәш аптырабрак калды. Мин тормыйча гына тегеңәргә:

— Соң син, тиле булмасаң, мине күрсәтер идеңмени? Котылырга телисең икән, «әнә шуннан алган идем, китте. Фәлән урам буйлап китте» дисәң ни була иде, — дидем. Шул сүзне әйтеп бетерә алмадым, ишек шакырдап ачылды, русча майлы сүзләр ычкындыра-ычкындыра:

— Ә, сез киңәш итешергә! — дип ике городовой безне җилтерәтеп алып чыктылар, җилтерәтеп югары меңгезделәр. Анда берсе околоточныйга, «ваша благороди» дип, безнең икәүләшеп ничек җавап бирергә киңәш итешкәнемезне сөйләде. Үзләре кыйнарга кулларын җәеп бастылар. Мин тагы аңлатмакчы булдым, булмады. Нишләргә? Кыйнаргамы, юкмы? дип көтеп

торганда гына ишек дөбердәде, яңа околоточный берлә городовойлар килеп керделәр. Минем өйдән тентү кайтты. Мин, ни таптылар, дип дерелди башладым. Кайткан околоточный күзене тутырып миңа караганның соңында: «Синең фамилияң?» — диде. Мин үземнең ялган фамилиямне әйттем. Зур төргәкне чиште.

— Бунлар синекеме? «Таң йолдызы» гәзитәләре.

— Минеке.

— Бунлар синекеме? Әллә никадәр рус гәзитәләре.

— Минеке.

— Бунлар бит конфисковать ителгән?!

— Редакциягә кирәк була да, шуның өчен яндырылмаган.

— Бунлар синекеме? Петербургта чыга торган, кып-кызыл партияләрнең көн дә конфисковать ителә торган гәзитәләре.

— Минеке.

— Бунлар кайдан?

— Редакциягә кирәк була.

Бер китап кеби нәрсәне алып:

— Бу синекеме? Бер партиянең рәсми яшерен гәзитәсе.

— Белмим, бәлки минекедер. Безгә күп йибәрәләр.

— Бу татар хәрефе?

— Минеке.

— Бу нәрсәгә?

— Үз исем-фамилиямне җыйдырып, клише ясатмакчы идем. — Околоточный аптырый, мин аптырыйм. Юбка урлаган диер идең, әллә никадәр студентларда гына була торган нәрсәләр. Урламаган диер идең, теге карак берлә киңәш итешкәннәр. Мин:

— Йә, мине нишлисез!? Йибәреңез. Күрәсез, берни юк!—дим. Шул ара да булмый, юбкалар югалткан хатын килеп керә. Ул картаеп беткән бер карчык. Аның өстендәге киемнәре бәлки үзеннән дә карт. Басып торуы, сөйләве, кыйлануы — һәммәсе кызгану гына китерә. Ул каракларны үз күзе

берлә күргән. Яшьле күзе берлә озак кына карап торганның соңында, теге каракка:

— Менә берсе шул иде, — ди. Миңа карап торганның соңында:

— Бу юк иде, тегесе бундый түгел иде, сары мыеклы иде, юк, бу юк иде, — ди. Минем эш тагы җиңеләйде, мин:

— Минем фатирымны беләсез, паспортым кулыңызда, ни бутыйсыз? Мине җибәреңез! — дим.

Околоточныйлар аптырабрак калалар. Теге, миңа җикергәне, кычкырганы тагы аптырый. Бер-берсенә карашалар, сөйләшәләр. Телефон берлә приставка киңәш итәләр. Мина: «Пристав килгәч чакырырмыз», — диләр. Бу юлы мине озатучы городовой сүгенми, төртенми. Мине аерып, бер чиста гына бүлмәгә ябалар. Лампа бирәләр. Иркенләбрәк сулыш алам, чынлабрак үземнең хәлемне уйларга тотынам. Хәлем бик шәп түгел. Алай-болай котылып чыга алмасам, бик тиз минем кем икәнлегем ачылачак. Иттифакый бер татар городовое күрдеме, минем ялган фамилиям аталары, бабалары, әбиләре, әниләре берлә күккә көл булып очачак. Аннан соң? Аннан соң мине төрмәгә озатачаклар. Минем татар арасындагы пакь исемемне чынлабрак былчыратыр өчен бәлки чынында шул юбка урларга кушып, уголовный бер эш ясаячаклар, уголовныйлар арасына ябып изәчәкләр. Уйлар матур түгел... Матур түгел уйдан туган нәтиҗә дә бик үк татлы түгел. Аның артыннан эленеп китә торган фаразлар, анларга буяу булып ягыла торган тойгылар да бик үк ялтыравыклы түгел. Нишлисең? Искеләрчә әйтсәң, сабыр итәсең, яңаларча әйтсәң, башны ими, һаваланып, һәр бәхетсезлеккә күкрәк киереп торасың! Ләкин шул яман уй, шул яман тойгы мине ташламый. Менә уголовный төрмә, менә мине әллә нинди бетле, сәләмә соры кием калдыкларына киендерәләр. Менә мине мадди вә мәгънәви сасы уголовныйлар бүлмәсенә ябалар. Менә минем күз алдында уйларга да күңел күтәрмәслек кабахәтлекләр, былчыраклыклар эшләнә. Менә мине судка алып баралар. Түгәрәкләнеп утырган заседательләр арасында зур корсаклы, кечкенә табагач лампа кеби мелтер-мелтер итеп тора торган күзле татар бае. Аның янында итче

руслар, аның янында кәкрәйгән ак якалы бер түрә кисәге, аның янында тагы сатучылар, түрәләр. Теге миңа: «Агай-энегә хөрмәт итмәгән кеше шулай булмый хәл юк инде. Без бит закон, хөкем итми хәлемез юк», — дигән кеби карап тора. Мәхкәмәне карарга килгән кешеләр арасында әллә никадәр татар, минем дустларым, әллә кемнән качкан кеби, арттагы урындыкка гына утырганнар. Дошманнарым, кызыл йөзләрене ялтыратып, аппак тешләрене ыржайтып көлеп утыралар. Һәммәсенең күзеңдә, йөзендә: «Ә, шулаймыни? Кызыл булып йөргән идең, менә ул кая бара икән! Фатиха юк шул!» — дигән сүзләрне укыйм. Суд башлана, мин бөтен көчемне җыеп, үземне коткарырга маташам. Прокурор, озын иттереп: «Татар халкы кеби сабыр, итагатьле халыкны котыртып йөри торган бу кешенең бүген чын ягы күренде. Бу ачлыктан аз гына үлми — дүрт баласыны кер юып тәрбия кыла торган карчыкның актык күлмәк-ыштаныны урлаучы икән», — ди. Мин кызарам, бүртенәм, сикереп торып җавап бирмәкче булам. Минем адвокат мине утырта. Теге татарлар тагы тешләрене ыржайталар. Адвокатның озын, утлы сүзләре дә ярдәм итми. Мине гаепле табалар. Мине — татарның оппозициясене алып бара торган кешене, мин татарга әдәбият ясыйм, дип алга сикереп чыккан татарның беренче мөхәррирене күлмәк-ыштан урлауда гаепле табалар. Мин шул золымга каршы сабыр итә алмыйм, кызам, бүртенәм, колакларым яна, башыма бөтен каным бердән йөгерә, торып әллә ниләр әйтмәкче булам. Колакны ярып чинаган тавыш мине сискәндереп җибәрә. Тамырлардан, сеңерләрдән үтеп, йөрәкнең иң ялангач җиренә барып бәрелгән ачы тавыш, кинәттән мине хыял галәменнән очырып, хакыйкатьнең, Русия хакыйкатенең алдына бастыра. Минем ачуым килүем, хурлануым оча, минем үземнең ямьсез хәлем онытыла, бөтен көчемне колагыма биреп, шул дуңгыз өткәндәге кеби чинауны тыңларга тотынам, ишекнең тишегенә барам. Менә әллә нәрсә еглый, чинау бердән туктала. Тагы зуррак тавыш белән башлана. Әллә ничә кешенең бердән атлавы, әллә нинди зур бер тирес нәрсәне өстерәү тавышы колакка ишетелә. Менә ишектә городовойлар күренәләр. Менә чын да анлар әллә кемне кычкыртып, акыртып, чинатып, өстериләр. Томанлы гына ут яктысында таза

гына, нык кына 25— 26 яшьләрендә бер марҗа күрәм. Ул хәзер чинамый, городовойларның аякларына ятып ялына: «Зинһар йибәренез, менә акчам, алыңыз! Бунда, төендә әйберләрем, алыңыз, зинһар йибәренез! Иремә ни әйтермен? Ул үтерер, полициядә кунган дип, тирә-күрше күземне ачырмас, зинһар йибәреңез!» — ди. Шул сүзләрне ул үзенең чын күңеленнән чыккан күз яшьләре белән майлый, үзе белгән тәреләргә, әүлияларга ялына, җалбара. Городовойлар таш багана кеби катып торалар. Анлар зур эш эшләгән кеби тентергә тотыналар, кесәсеннән алтмыш әллә ничә тиен акчасы, кулындагы төененнән күлмәк-ыштан кеби әйберләр чыга.

— Бу әйберләрне кайдан урладың?

— Беркайдан да урламадым, үземнеке. Менә кофтам, өстемдәгесе белән бер очтан, керчегә биргән идем, дустым хатынның именинасында утырдым, шуннан кайтам.

— Юк, син әйт! Кайдан урладың?

— Валлаһи, билләһи, таллаһи, урламадым, мин урлый торган кеше түгел. Минем ирем приказчик. Безнең үз йортымыз бар, Аллага шөкер. йибәренез! Ирем, белсә, үтерер. Алыңыз әйберләремне, акчамны, йибәреңез.

— Юк! Пристав килгәнчә торасың.

Тагы еглау, тагы ялбару, тагы догалар. Бер городовой минем ишекне ача. Берсе тотып теге хатынны кертә башлый, берсе мине тартып чыгара. Без теге марҗа белән кара-каршы киләмез. Нык, таза, тәмле аш пешерә белгәне, пешерүдән битәр ашый белгәне күренеп тора торган гади бер мещан хатын. Чинау тагы башлана, күз яше чиләкләп ага. Ишек ябыла, йозак бикләнә. Мин үземнең кем икәнлегемне онытып:

— Ник аны тоттыңыз? Ни дип ябасыз? — дип городовойларга бәйләнәм. Берсе кулын күтәреп, русча гадәттә әйтелә торган сүзләрене әйтеп, өстемә килә, сугып йибәрмәкче була. Берсе тегеңәргә күзе берлә ишарә кыла, теге, бераз җәберләнеп, сүгенергә тотына. Икенчесе: «Безнең эш түгел, урлаган. Пристав теләсә нишләсен», — ди. Ишекне ачып, мине баягы караңгы бүлмәгә кертәләр. Андагы исерек тагы әдәпсез генә сүгенә. Андагы бер карак

сенләп-сенләп городовойларны сүгә башлый. Ишек ябыла. Бик озак күрше бүлмәдән ыңгырашу тавышы килә, ярыкны табып без марҗа белән сөйләшәмез. Ул үзенең дустының именинасыннан кайтып килә икән, азрак соңгарак калган, күрәсең, бакча буйлап төшеп килгәндә городовой тоткан да китергән. Ул сөйләп бетерә алмый, городовой безгә сүгенеп кычкыра, теге хатынның бүлмәсенә кереп лампаны ала. Биш-ун минут вакыт үтми, тегенең ишеге ачыла. Акрын гына сөйли торган тавыш ишетелә, бер городовой допрос ала:

— Син кем? Ирең кем? Иртәгә полиция аркылы сине этап белән, шнурлы книга белән иреңә тапшырырга кирәк!

Теге марҗа тагы чиный, тагы еглый, тагы җалбара!..

— Зинһар алай итмә! Зинһар акчамны да ал, әйберләремне дә!

— Закон.

Акыртын гына городовой хатынның колагына шыпырт кына сөйли башлый. Без бернәрсә ишетмибез, теге хатын гына: «Юк, юк», — дип җавап бирә. Бүлмәдә әллә нәрсә, маташу тавышы күтәрелә. Хатын: «Юк, юк! Кит, кит!» — дип кычкыра, әллә нәрсә ауган кеби була, селкенәләр, тыпырчыналар, мышныйлар, мин диварны кагарга тотынам. Теге карак сүгенергә тотына, безнең ишеккә каравылда ике городовой килеп: «Сөякләреңезне көл итәрмез», — дип ишек ача башлыйлар. Анлар сүгенә, без кычкырышамыз. Ачуның кызуы кайта. Тагы тынамыз. Күрше бүлмәдә тагы еглау башлана. Марҗа баягыдан да кычкырып еглый.

— Мин нишләдем, ай Аллам! Мин нишләдем... Бу гөнаһны кая итәрмен? Иремә ни күз белән күренермен? — Без аны җуатамыз:

— Син үзен тиле, ник ирек бирдең?

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Тоткар* — тоткын.

*Абелхәят* — тереклек суы.

*Ихтилял* — баш күтәрү, фетнә, бунт.

*Иттихады ислам* —и слам берлеге.

*Диван* — дәүләтнең югары советы.

*Ифтира* — яла ягу.

Мөнбәр — трибуна.

*Тиҗарәтханә* — сәүдә йорты.

*Нoктаи назар* — караш.

*Монзарә* —бәхәс.

*Харикылгадә* —гадәттән тыш.

Тәвә —дөя.

*Моталәгә* — уку, өйрәнү.

*Кушану* — тагу.

*Сәнаигы нәфисә* — матур сәнгать

*Сайау* — санау.

*Сәгадәт* — бәхет.

*Ханис* — ант бозучы, ялганчы.

*Сәрве* —кипарис.

*Хофиялек итә торган* — яшерен, серле яши торган.

*Кальга* — крепость.

*Челем* — труба.

*Пәйнир* — сыр.

*Гаскәр* — гаскәри, солдат.

*Куллык* — перчатка.

*Кибарлек* — олысыманлык, һавалык.

*Фигълияткә чыгу* — эшкә ашу, чынга чыгу.

*Сайау* — санау.

*Мөхалиф* — каршы.

*Ил* — умарта.

*Сәнҗак* — байрак.

*Иттифакый* — очраклы.

*Мәхкәмә* — суд.

*Тирес* — кире

*Хасыйле* — кыскасы.

*Ятап* — этап.

**Бер тоткарның саташуы** — Хикәя Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» наширлегендә 1913 елда басылып чыга. Сигезтомлыкта: 5 нче җилд. Титул биттә: «Йосыф әфәнде Акчура җәнаблары тарафыннан язылмыш мөхәррирнең мөфәссал тәрҗемәи хәле, рәсеме вә кульъязмасы илә табгъителде» диелсә дә һәм башка кайбер әсәрләре титулында да шулай язылса да, бу мәкалә «Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асәре» сигезтомлыгында бөтенләй басылмаган.

Гаяз Исхакый үзе бу әсәрен «хыялый роман» дип атый.

Ш.Мөхәммәдьяров истәлегендә Г.Исхакый, «көз көне [1907 ел] 26 октябрьдә Казаннан сакчылар илә Мәскәүгә җибәрелә. Анда Мәскәүнең мәшһүр, ул елларда сәясиләр берлә тулы «Бутырка» төрмәсендә ике атна тотыла. Беренче декабрьдә ятап белән Архангель губернасына Пинега шәһәренә китерәләр», диелә. *(Гаяз әфәнде — Вакыт, 1913, 2 май.)*

Г.Исхакый 1908 елда Пинегада яшәгәндә Россия Эчке эшләр министрлыгына үзенең сөргенлек срогын чит илдә үткәрү өчен рөхсәт сорап гариза бирсә дә, җавап килгәнен көтеп тормыйча, аннан качкан. 1908 елның 26 августында Полиция департаментының Исхаковка чит илләргә чыгарга рөхсәт бирүе турында Казан губернаторы Казан губернасы җандарм идарәсенә хәбәр җибәрә: «Полиция департаменты узган июль аеның 26 сында 105876 номерлы белешмә белән Самар губернасы Бөгелмә өязе Лашман авылы крәстияне Мөхәммәдгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаковның эше яңадан каралганын һәм эчке эшләр министры әле телгә алынган кешегә чит илләргә чыгарга рөхсәт бирелгәнлеген, ул кеше 1910 елның 30 сентябренә чаклы империя җиренә әйләнеп кайткан очракта махсус киңәшмәнең аңа кагылышлы карары гамәлгә ашырылачагын миңа хәбәр итте.

Полиция департаменты Архангель губернаторына гамәлгә ашыру өчен хәбәр иткән әлеге карарның 1907 ел, 28 октябрьдә кабул ителгән 13345 номерлы язмага өстәлүен Сез - Галиҗәнабның исенә төшереп куюны үземнең бурычым санадым. *(ТМА, 199 ф., 1 тасв., 538 эш, 110 б.)*

Г.Исхакый «Тәрҗемәи хәлем»ендә болай яза: «Сөргендә озын кала алмадым, качмак планнарыны кордым. Ниһаять, 1908 нче сәнәсенең август соңнарында... Архангель шәһәренә кадәр дүрт көн, дүрт кич... кача-поса хәрәкәт итеп, Архангельга килдем һәм аннан Петербургка киттем һәм анда ялган паспорт белән яшәдем... 1909 елның май аенда ялган паспорт белән Төркиягә килдем». Шул елның көзендә Г.Исхакый тагын Петербургка кайта. Шул кайтуында ул 1910 елның яз-җәй айларында Финляндиядә дүрт ай яшәп ала. «...Төркиягә киттем. Бу китешем махсус план белән иде. Бу елның 30 сентябрендә минем сөрген вакытым тәмамлана. Мин сөргеннән качканнан бирле Төркиядә яшәдем дип бер ялган кәгазь ясатып һәм шуны хөкүмәткә тапшырып, сөрген вакытым өчен хисап бирергә теләдем... Ис- танбулда яшәвемне раслаган бер нәрсә алдым... һәм аны рус консуллыгында раслаттым. Русия Эчке эшләр идарәсенә җибәрдем, ждвап көттем. Илемә кайткач эшләячәк эшләрем хакында ачык бер планым да булса да, бу кабул итү җавабы мине фаш итү була күрмәсен дип курыктым... Истанбулда тору мәҗбүриятендә калдым»,—дип яза Г.Исхакый.

Ләкин 1909 елның 21 мартында Полиция департаментының качкын Исхаковны эзләү турында күрсәтмәсе чыккан була инде. Казан жандармнар башлыгы Петербургта үзенең агентурасын җәелдереп җибәрә. Әдипнең Петербургка беренче тапкыр кайтуында шымчылар аның эзенә тиз генә төшә алмыйлар. Алар, белеп алып, Казанга хәбәр иткәндә, Г.Исхакый Петербургтан китеп барган була инде. Полковник Калинин Петербургтагы охранка бүлегенә яза: «Сез Галиҗәнабкә шуны белдерергә тиешмен: агентураның хәбәр итүенә караганда, Полиция департаментының шушы елда 21 март 151020/ 36 номеры белән чыгарган күрсәтмәсе нигезендә эзләнүче Мөхәммәдгаяз Исхаков партия эшләре белән Истанбулдан С.-Петербургка килеп төшкән. Ул Пантелеймов

урамындагы 1 нче йорт, 2 нче кв. яшәүче Петербург мулласы Лотфулла Исхаковларга еш кына барып йөри икән. Мулла өендә гадәттә халык күп булу сәбәпле, Г.Исхаковны Мөхәммәдьяров фатирында күзәтү кулайрак булырдыр.

Гаяз Исхаковның агентура төшереп алган фоторәсемен дә юллыйбыз: ул урта буйлыдан озынрак, таза гәүдәле, озынча йөзле, аурупача киенә.

Г. Исхаков Казанда яшәүче, һәм үзенең китапларын татар телендә чыгаручы Хөсәен Әбүзәров дигән кеше белән хат алыша». *(ТМА, 199 ф., 1 тасе., 675 эш, 93 б.)*

Г.Исхакыйның икенче тапкыр 1909 елның көзендә Петербургка кайтуын да полковник Калининга шактый соң җиткерәләр. Петербург охранка бүлегенә ул 1910 елның 1 февралендә тагын үтенеч яза: «...язучы һәм публицист Гаяз Исхаков 1909 елның декабрендә яисә бу елның гыйнвар башында ялган исем белән Төркиядән Петербургка юнәлгән. Нинди исем белән йөрүе билгесез. Башкалага килүенең максаты — Думадагы Мөселман фракциясе аркылы ниндидер мәсьәләләрне үткәрү. Шул ук хәбәрләрдән күренгәнчә, С.-Петербургта Исхаковның танышлары бар — Дәүләт думасы әгъзасы Садретдин Максудов, Хатын-кызлар курсларында укучы Әминә Терегулова һәм югары уку йортына керергә хәзерләнеп ятучы Шакир Мөхәммәдьяров. Исхаков бу кешеләрдә булгаларга мөмкин, ләкин алардан хәбәр алып булмас, аның турында сөйләмәсләр, хәтта Исхаковны кисәтергә дә мөмкиннәр.

Бу хәбәрләрне тикшерү нәтиҗәләрен миңа белдерергә кушуыгызны үтенәм.» *(199 ф., 1 тасв.., 675 эш, 192 б.)* Төркиядән шул икенче кайтуында Г.Исхакый Петербургта бер еллап яшәсә дә, шымчылар аның эзенә төшә алмыйлар.

Ниһаять, Г.Исхакый Төркиядән Алманиягәме, әллә Франциягәме китәргә дип икеләнеп торганда, 1911 елның октябрь аенда Петербургтан Заһид Шамилдән хат килеп төшә. Ул яңа бер әдәби мәҗмуга чыгара башларга теләүләре турында яза һәм Г.Исхакыйны мәҗмуга идарәсендә эшләргә чакыра.

Г.Исхакый: «Бу мәктүб икеләнүләремне бердән хәл итте һәм атна- ун көн эчендә җыенып иске ялган паспорт белән Петербургка килдем».— ди.

Шул килүендә ул тотыла һәм Петербург төрмәсенә ябыла. «Петербургның төрле төрмәләрендә ике айга кадәр калганнан соң, мине элеккеге сөрген җирем — Архангель вилаятенә җибәрделәр. 4035 нче Архангель төрмәсенә яптылар. Бу дәвердә безнең оешма әгъзаларының бик күбесе тотылган, бик күбесе каты җәзаларга тартылган булганга, әллә кулларына берәр документ төште микән дип, бик куркулы көннәр, атналар кичердем. Мине бигрәк тә гади төрмәдән алып сәясиләр төрмәсенә күчермәүләре куркытты. Тотылган вакытымда янымда өч сумлап акча бар иде. Шул акча белән өч ай буе төрмәдә калып, бик кысынкылык кичердем, өч ай буе бер үк эчке киемнәрдә ятып, бетләдем»,—дип яза Г.Исхакый «Тәрҗемәи хәлем»дә. Ниһаять, аны этап белән Мезень шәһәренә сөрген вакытын тутырырга озаталар. Әдипнең Ш.Мөхәммәдьяровка язган бер хатында без мондый юлларны укыйбыз: «Мин үземнең тотылуымнан алып бу көнгә кадәр булганнарны китап итеп язмакчы булам... Юл буе йөдәгәнем — күлмәк-ыштанның җитмәве, юрган-мендәрнең булмавы, акчаның Петербург төрмәсе-нең конторында калуы булды. 13 нче февральдән 20 нче мартка кадәр минем шул модный Истанбул пальтәм — мендәр дә, юрган да, түшәк япмасы да, кием дә булды... Юлда бер тиен акчасыз бардым. Чәй юк, шикәр юк. Көненә ун тиен кормовой бирәләр. Шуңарга һәммәсен эшлә. Шул пальтәм, шул башымдагы кәпәчем берлән биш йөз чакрымлы ятабка чыгып киттем. Юлдагы ачлыкны, бетләүне сорама да инде». *(Ш.Мөхәм- мәдьяров.— Гаяз әфәнде — Вакыт, 1913, 2 май.)*

Мезеньда полиция күзәтүе астында Г.Исхакый бер елдан артык яши. Көннәрен шактый төшенкелек халәтендә кичерә, бу чорда бердәнбер хикәясен — «Бер тоткарның саташу»ын яза. 1913 елның март аенда Россиядә Романовларның хакимиятенә 300 ел тулу мөнәсәбәте белән амнистия игълан ителә. Шул амнистиягә эләгеп, Г.Исхакый да азат ителә.

Күренгәнчә, сөрген чорында Г.Исхакый Истанбулда ике тапкыр, Петербургта өч тапкыр яшәп, иҗат итеп ала.

Ә Казанда Жандармерия идарәсендә Г.Исхакыйга өстәмә гаепләр эзләү дәвам итә. Полковник Калинин Петербургтан Исхакыйның квартирасын тентегәндә табылган әйберләрне Казанга алдыра. Архивта 16 данә зур форматлы кәгазьдә алар га җентекле тасвирлама теркәлгән. *(ТМА, 199 ф., 1 тасв., 872 эш, 149-156 б.)*

Кызганыч ки, «Бер тоткарның саташуы» хикәясе Г.Исхакыйның шул өченче тапкыр Петербургка кайткач булган вакыйгаларны гына эченә ала, гүяки ул авторның хәвефләр белән тулы тормышының бер читен генә ачып күрсәтә. Әдипнең сөрген чорына караган вакыйгалар Жандармерия документларында күбрәк чагылган.

Г.Исхакыйның этап белән Мезеньга сөрелүе һәм анда яшәве турында беркадәр мәгълүматны рус язучысы, әдип белән бергә сөргендә булган Александр Яковлевич Аросевның (1890—1937)1933 елда басылып чыккан «Тамырлар» («Корни») исемле романында да табарга мөмкин. Анда әдип хәтта үз исеме белән бирелгән.

*Соңгы әсәремнең төп нөсхәсе* —сүз Г.Исхакыйның 1912 елда язып тәмамлаган «Зөләйха» драмасы турында бара. Драма 1917 елда цензура бетерелмичә бастырылмаган һәм сәхнәгә дә чыгарылмаган. «Зөләйха» беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан әзерләнеп, 1917 елның 17(30) мартында Казанның зур драма театрында уйнала. Китап булып 1918 елда басылып чыга. Хикәядә авторның драма исемен атамавы һәм эчтәлегенә бик кермәве дә саклык өчен эшләнгән. «Тәрҗемәи хәлем»ендә әдип: «Темасы белән бу әсәремне бик мөһим бер әсәр дип санаганга, тикшерүгә куярга теләдем»,—ди.

*Шәфика, Зәйнәп* — кульязма «Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый кызларның чын исемнәрен яза: «Мин үзем белән бергә Балкан сугышы

вакытында Төркиягә шәфкать туташы буларак килгән университет студентларыннан Гөлсем һәм Мәрьям исемле ике кызны китердем»,—ди.

1912 елда Балкан-Төрек сугышы чорында, С.-Петербургта Югары хатын-кызлар курсларында укучы дүрт кыз шәфкать туташлары булып Төркиягә китәләр. Алар: Чистайдан Өммегөлсем Камалова, Петербургтан Рокыя Юнысова, Ростовтан Мәрьям Паташева, Ташкенттан Мәрьям Якупова. Кызларны бирегә Фатих Кәрими алып килә һәм эшләячәк шифаханәләренә урнаштыра. Соңыннан да ул һәрчак кызларның хәлләрен белеп тора, дәрәҗәле очрашуларда да кызлар белән бергә була. Кызлар һәр урында, һәр эштә уңганлыклары белән гаҗәпләндерәләр, сокландыралар. Менә аларга европалы ханымнарның бәясе: «һич көтелмәгән җирдә, тәмам европалы ханымнар кыяфәтендә Русияле мөселман кызларын күрү аларны бик гаҗәпләндерде. Эштә, урамда, җәмәгать оешмаларында, халыклар арасында үзләрен тота белүләре, булдыклылыклары белән алар һәр очраган кешене үзләренә хөрмәт белән карарга мәҗбүр итәләр». Кызлар шәфкать туташы булып эшләү белән генә чикләнмиләр, Төркиянең җәмәгать тормышында актив катнашалар, хатын-кыз хәрәкәтен оештыруда башлап йөрүчеләрдән булалар. Садр әгъзам (Төркия солтанының баш вәзире — премьер министры) Мәхмүд Шәүкәт паша кызларга: «Мөселман хатын-кызларының зур кальбле, галиҗәнаб икәнлеген сез гамәлдә күрсәттегез»,— дип, күп рәхмәтләр әйтә. *(Мәсгут Гайнетдин.— Халык каһарманнары — Сөембикә, 1997, 6 сан.)*

Бу каһарман кызларның берсенең — Мәрьям Якупованың соңгы язмышы турында тәфсиллерәк мәгълүматлар да бар. Сугыштан соң Мәрьям Петербург медицина институтын тәмамлый, туган шәһәре Ташкентка кайта. 1920 елда шәһәрдә беренче акушерлык техникумы ачыла. Башлап йөрүчесе — Мәрьям Якупова. 1927 елга кадәр ул шул техникумда укыта, үзбәк хатын-кызлар институтында курслар алып бара, соңыннан поликлиникада эшли. Табибә М.Якупова 1971 елда 84 яшендә вафат була. *(Рафаэль Зарипов.— Мәрьям ана.— Сөембикә, 1997, 6 сан.)*

Г.Исхакыйның «Зөләйха» драмасын уку мәҗлесендә әдипнең якташы, Чистай кызы Өммегөлсем Камалова һәм Төркиягә шәфкать туташы булып барган ике Мәрьямнең берсе—әдипнең хикәядә «доктор кыз үзенең сөякләрене, буыннарыны оныта» дигән сүзләренә караганда, ул елларда С.-Петербургта медицина институтында укып йөргән Мәрьям Якупова катнашкан булса кирәк.

*Менә зур йорт... ачык ишек безне каршы ала* — «Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый «Зөләйха» пьесасын җыелышып укырга дип килешенгән урыннар турында болай яза: «Беренче мәҗлес генерал Шәех Галинең хатыны Гөлсем ханымның өендә булачак... Икенчесе... Заһид Шамил өендә булачак.»

*«Иттихады ислам» җәмгыяте* — Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләренең әдәби-мәдәни оешмасы (1901—1905).

*Лодзь* — Польшадагы шәһәр.

*Яңа бистә* — Казанның көньягында урнашкан бистә. Хәзер шәһәрнең Идел буе районына керә.

*Шиһабеддин әл-Мәрҗани* (1818—1889) — философ, дин галиме һәм шәркыйәтче.

Габделкаюм әл-Насыйри (1825—1902) — мәгърифәтче, галим, әдип һәм педагог.

*Маркс Карл* (1813—1883) —немец философы.

*Ташаяк* — һәр ел яз көне (май аенда) булып килгән ярминкә; Казанның Кремльгә якын урынында, хәзерге Үзәк стадион каршындагы мәйданда булган.

*...мин ул әсәремне китапчыга бик кыйммәт иттереп саткан идем* — сүз Г.Исхакыйның Казанда 1899 елда басылып чыккан «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» исемле хикәясе турында бара.

*Кашгар* — Кытайның иң көнбатыш өлкәсе.

*Әдернә капусы зиярәте* — Истанбулда «Әдернәкапы шәһитлеге» зираты. Г.Исхакый да, Й.Акчура да шул зиратта күмелгәннәр.

*Сөембикә* (XVI гасыр) — ханбикә, татар ханнары Сафагәрәй һәм Шаһгалинең хатыны, 1551 елда тоткын итеп Мәскәүгә озатыла һәм шунда үлә.

*Әхмәтҗан.., Зөләйхалар, Әхмәтләрне* — «Зөләйха» драмасындагы персонажларга ишарә.

*Салих пәйгамбәр таштан тәвә дә чыгарган* — дини ривайәт буенча: сәмуд халкын хак дингә өндәргә килгән Салих пәйгамбәрдән үзенең Алла вәкиле икәненә ышандыру өчен могҗиза күрсәтүен сорыйлар: «Менә шул кара таштан дөя чыгар»,—диләр. Салих пәйгамбәр таягы белән сугуга бер ана дөя пәйда була. Аңа карап сәмудлар барыбер күктәге Аллага иман китермиләр, пәйгамбәр китү белән дөяне суеп ашыйлар. Г.Исхакый шул ривайәткә ишарәли.

*Матур уй, татлы фаразлар берлән сәгать үткәнне сизми дә калабыз* — «Тәрҗемәи хәлем»ендә әдип: «...без төнге сәгать дүрткә кадәр кунакта калдык... Гөлсем ханымның өендәге мәҗлес искиткеч матур булды, әсәрне һәркем ошатты. Бары соңгы пәрдәдәге фәрештәләр һәм Газраил безнең әдәбиятыбызда беренче тапкыр сәхнәгә чыгарылганга... фәрештәләр арасындагы аерма турында гына бераз бәхәс булып алды»,—ди.

*Әллә мин төп нөсхәне кызларга биримме? Юк ла, мин бит инде алты ел качып тордым, йиденчесендә килеп тотмаслар,*— Г.Исхакый икеләнүләрен җиңеп, әсәрең кызларга биреп җибәреп, «Зөләйха»ны эзсез югалудан коткарып кала. Чөнки икенче көнне үк ул кулга алына. Димәк, Заһид Шамил өендә җыелып драманы икенче тапкыр уку бөтенләй булмый кала. «Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый полиция кулына эләккәч: «Кичә «Зөләй- ха»ның оригиналын кызларга бирүемнән мәмнун идем», ди.

*Әлҗәзаир* (Алҗир), Тунис — Төньяк Африкадагы мөселман дәүләтләре.

*Беренче мәртәбә мин аны Чистай төрмәсендә язарга тотындым.*— Г.Исхакый үзенең «Зиндан» исемле повестенда (1907) болай ди: «Мин хәзер «Отпавший» исемле бер пьеса язарга хәзерләнә башладым. Беркөнне пьесаның пәрдәләрен бүлеп, планын бетереп, язарга гына тора идем, старший кереп безнең бүлмәдә тентү ясый башлады... Һәм дә минем «Отпавший»ымның да планын алып чыкты. Шакир Мөхәммәдьяров «Гаяз әфәнде» исемле мәкаләсендә: «Бу әсәр... мужик үрәтниктән җәбер күреп килгән мөселман гаиләсен тасвир иткән дәһшәтле, авыр бер трагедиядер. Исеме — «Отпавший» — «Мәкруһ», яхуд «Зөләйха»дыр»,—ди. (Гаяз әфәнде,— Вакыт. 1913, 2 май.)

*Мин елгалары башка тарафка ага торган, җилләре башка яктан исә торган ... халыкның йиренә күчтем* — сүз биредә Г.Исхакыйның 1910 елның көзендә Истанбул шәһәренә килүе турында бара.

*Бер тәрәзәмнән бугазның иң матур боргаланган йирләре...*— сүз Истанбул шәһәрен Азия һәм Европа өлешләренә аерып торган Босфор бугазы турында бара.

*Солтан Фатыйхның кальгасы* — Солтан Мөхәммәд Фатыйх Икенче («Яулап алучы», 1444—1446, 1451—1481); аның кальгасы — үзе салдырган Топкапы сарае.

*Мәрмәрә диңгезе* — диңгезнең исеме ак мәрмәр ятмалары булган утрау исеменнән алынган.

*Мәхмуд Икенче* — 1808—1839 елларда Төркия солтаны.

*Кандилле* — Истанбул шәһәрендә бер бистә.

*Ноябрьнең соңгы моңлы җылысында йөзем, инҗир исе мине озатып калды.* — Г.Исхакый 1911 елның октябрь аенда Истан- булдан туган иленә кайтырга чыга.

*Сулар кичтем, сахралар үттем, торачак шәһәремә килеп йиттем* — Г.Исхакый 1911 елның октябрендә Петербургка кайтып төшә.

*«Ревизор»* — Н.В.Гоголь (1809—1852) комедиясе.

*Печемене Идрис пәйгамбәр печкән* — дини риваятьтә: Идрис пәйгамбәр бик галим һәм гаҗәеп дәрәҗәдә сабыр кеше булган. Адәм балаларына күлмәк тегеп кияргә дә ул үзе өйрәткән. Киеменең бик килешле итеп тегелүен анлату өчен Г.Исхакый шушы риваятькә ишарә итә.

*Хөллә* — өс киеменең (чапанга охшаган) бер төре.

*Көпе* — куй йоныннан сырып тегелгән бишмәт, тун кебек кием.

*Тузак* — каен тузыннан ясалган савыт.

*Невский буйлап* — Петербург шәһәренең тимер юл вокзалыннан үзәккә таба сузылган (төп) проспекты буйлап.

*Менә әллә кем каты кулы белән арт яктан җилкәмнән кысып тота* — Г.Исхакый Петербургта 1912 елның 26 гыйнвар көнне кулга алына. (ТМА, 199 ф., 1 тасе., 948 эш, 53 б.)

*Городовой* — патша Россиясендә: шәһәр полициясенең түбән чины.

*Околоточный* — патша Россиясендә: шәһәр полициясенең кечерәк районга — околотокка күзәтчелек итүче чины.

*Сарай мәйданы* (Кышкы сарай мәйданы) — Кышкы сарай — С.-Петербургта рус архитектура һәйкәле. 1754—1762 елларда В.В.Растрелли тарафыннан төзелгән. Рус императорларының, ә 1917 елның июленнән Вакытлы хөкүмәтнең резиденцияләре булып хезмәт итә. Бина 1917 елның 7—8 ноябрь төнендә большевиклар кулына күчә. 1918 елда бер өлеше, 1922 елда бөтен бинасы белән Эрмитажга бирелә. Сарайның фасадлары Нева елгасына, Адмиралтействога һәм Сарай мәйданына чыга.

*Камәт төшеру* — намазга кереш ясау.

*«Таң йолдызы»* — Казанда Г.Исхакый оештырган беренче рәсми «сәяси, әдәби һәм фәнни» гәзитә (18 май — 17 ноябрь. 1906), барлыгы 65 сан чыккан.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.225-253